وَاعْتَصِمُوا بِحَبْلِ اللَّهِ جَمِيعًا وَلَا تَفَرَّقُوا

Ий мөэминнәр! Барчаларыгыз да берләшкән хәлегездә Аллаһ арканына, ягъни Аның диненә ныклап ябышыгыз! Һәм һич тә аерылмагыз һәм бер-берегездән киселеп, төрле юлларга китмәгез! *(Коръән, 3:103)*

6+

Дин вә Мәгыйшәт

№10 (231). Октябрь – 2014 / Зөлхиҗҗә – 1435

ТАТАРСТАН МӨСЕЛМАННАРЫ ДИНИЯ НӘЗАРӘТЕ БАСМАСЫ

4-5 бит

АЛЛАҺ ИЛЧЕСЕНЕҢ ДӘВАСЫ

Татарстан мөфтиенең мөхәррәм ае һәм 1436 ел башлану уңаеннан МӨРӘҖӘГАТЕ

Бисмилләһир-рахмәнир-рахим!

Әссәләәму галәйкүм үә рахмәтүллаһи үә бәракәәтүһ!

Мөхтәрәм мөселманнар!

25 октябрьдә ай календаре буенча яңа ел башлана. Мөселман дөньясы 1436 һиҗри елына аяк баса. Яңа елны башлап җибәрүче мөхәррәм ае мөселманнар өчен аеруча әһәмияткә ия. Мөхәррәм ае ызгыш-талашлар, низаглар тыелган 4 айның берсе.

Коръәндә әйтелгән: "Күкләрне вә Җирне яралткан көннән алып, Аллаһның хисабына күрә, айларның саны унике; аларның дүртесе сугышу хәрам айлар булып хисаплана. Диннең дөрес хисабы шулдыр" ("Тәүбә" сүрәсе, 36 нчы аять).

Пәйгамбәребез Мөхәммәд (с.г.в.) үзенең бер хәдисендә: "Рамазан уразасыннан соң иң фазыйләтле ураза мөхәррәм аенда тотылган уразадыр", - дип билгеләп үтә. Икенче бер хәдисендә: "Мөхәррәм аенда бер көн ураза тоткан кешегә 30 көн ураза тоткан кадәр савап язылыр",- ди.

Мөхәррәм ае башланган көннәрдә елыбыз хәерле узсын дип догалар кабатлыйк һәм Раббыбыз һәркайсыбызга шушы күркәм айда башкарган изге гамәлләребез, тоткан уразаларыбыз өчен әҗер-савапларны мулдан бирәчәге хакында онытмыйк.

Татарстанлылар динебез юлында, изге гамәлләр кылуда елдан-ел зуррак, күбрәк тырышлык куялар. Бу татар халкының рухи яктан ныгуын, үсүен күрсәтә. Төрле конфессияләрнең үзара хөрмәте һәм татулыгы исә Россия үсешенә нигез булып тора.

Елыбызны Аллаһы тәгалә рәхмәтенә ирешергә теләп, яхшы эшләрдән башлыйбыз икән, алдагы көннәребез дә, иншә Аллаһ, матур гамәлләр, чиста ниятләр белән тулыр.

Аллаһы тәгалә яңа елда барчабызга уңышлар насыйп итсен! Республикабызга, өйләребезгә бәрәкәт, ил-көннәребездә тынычлык, иминлек бирсен! Амин.

Татарстан мөфтие Камил хәзрәт СӘМИГУЛЛИН

9 бит

ХАЖЛАРЫГЫЗ КАБУЛ БУЛСЫН!

КЫРЫМ МӨСЕЛМАННАРЫ ХЕЗМӘТТӘШЛЕККӘ ӘЗЕР

Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин җитәкчелегендәге Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте делегациясе Кырымда үткәрелгән фәнни-гамәли конференциядә катнашты. "Кырым ислам мирасын саклауның һәм өйрәнүнең актуаль проблемалары" дип аталган сөйләшү Үзбәк хан мәчетенә 700 ел тулуга багышланган иде.



Конференция Кырымның дини тарихын, кырым татарлары мәдәниятен өйрәнү һәм киң җәмәгатьчелеккә таныту, мөселманнар арасында элемтәләр булдыру, тәҗрибә уртаклашу максатыннан уздырылды. Фәнни-гамәли чарада Россиянең һәм чит илләрнең Алтын Урда чорын өйрәнгән галимнәре, күренекле дин әһелләре катнашты.

Конференция Симферополь шәһәрендә үтте. Чара кысаларында делегатларга Үзбәк хан мәчете тарихына багышланган фильм күрсәттеләр, "Кырым мәчетләре" дип аталган фотокүргәзмә дә оештырылган иде.

Үзбәк хан мәчете иң борыңгы мәчетләрдән санала. 1312 елда Алтын Урда тәхетенә килгән Үзбәк хан Иске Кырым шәһәрендә мәчет һәм югары дини белем бирүче мәдрәсә төзергә боера. Мәчет төзелеше 1314 елда башлана. Тарихи язмалардан күренгәнчә, 1512-1513 елларда ул җамигъ мәчет булып тора. Мәдрәсәдә Коръән өйрәнәләр, фәлсәфә, гарәп теле, риторика, астрономия, мантыйк, канун дәресләре укытыла. Мәдрәсә тәмамлаганнар мулла, казый, дин белгечләре булып ислам динен тараталар. Бүгенге көндә мәчетнең беренче төзелешеннән төньяк дивары гына сакланган.

Татарстан мөфтие Үзбәк хан мәчетендә һәм Инҗәбәк Хатун мәдрәсәсе комплексында булды. Әлеге тарихи урыннарга экскурсияне Дәүләт Эрмитажы фәнни хезмәткәре, тарих фәннәре докторы, Иске Кырым археологик экспедициясе җитәкчесе Марк Крамаровский уздырды. Аның сүзләренә карaганда, Иске Кырымдагы мәдрәсә Көнчыгыш Европадагы иң борыңгы мәдрәсәләрдән санала. Аның сакланып калуы һәм мәчет буларак файдаланылуы үзе бер могҗиза. Хәзерге вакытта мәчет һәм мәдрәсә комплексы реставрация һәм дәүләт тарафыннан яклау-саклау көтә. Конференциядә катнашучылар, дәүләт эшлеклеләрен Иске Кырымдагы тарихи-дини корылмаларны торгызырга һәм сакларга чакырып, резолюция кабул иттеләр. Шулай ук кырым татарлары тарихи һәм мәдәни һәйкәлләрен төзекләндерү һәм саклау буенча максатчан программалар эшләү, тормышка ашыру кирәклеге әйтелде.

Мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллин һәм аның урынбасары Рәфыйк Мөхәммәтшин Татарстанның Кырымдагы даими вәкиллегендә дә булдылар. Бирелә алар вәкиллек җитәкчесе Илмир Тимергалиев белән очраштылар. Сөйләшү милли-мәдәни һәм дини юнәлешләрдә хезмәттәшлек итү хакында барды.

Татарстан вәкилләре кардәш халыклар - кырым татарлары тарихы, рухи мирасы һәм бүгенге көндә алып барылган эшләре белән якыннан танышканнан соң, төрле рәсми һәм дини сөйләшүләрдә катнаштылар. Шундый сөйләшүләрнең берсе Кырым мөселманнары Диния нәзарәте рәисе Әмирали Әблиев белән булды. Татарстан һәм Кырым мөфтиләре ике мөфтият арасындагы хезмәттәшлек хакында әңгәмә кордылар. Кырым мөфтие фикеренчә, Татарстан күп юнәлешләрдә үрнәк булып тора һәм алар безнең республика белән хезмәттәшлеккә һәм диалог корырга, тәҗрибә уртаклашырга әзер.

Камил хәзрәт шулай ук башка мөфтиләр белән бергә Кырымның дәүләт телевидениесе тапшыруларында да катнашты.

ДИННЕ СӘЯСӘТКӘ КАТЫШТЫРМАСКА

Татарстан мөфтие урынбасары Рөстәм хәзрәт Хәйруллин Мәскәүдә "Дин һәм Дөнья" дип аталган икенче халыкара форумда катнашты һәм Татарстан мөфтие исеменнән чыгыш ясады.

Хәзрәт республикадагы динара мөнәсәбәтләр, мөселман өммәте һәм православие вәкилләре арасында алып барылган хезмәттәшлек хакында сөйләде. Динара татулык белән җәмгыятьнең рухи-әхлакый ягын кайгыртып булуы хакында әйтте.

Форумда фән эшлеклеләре, иҗтимагый оешмалар вәкилләре, дин әһелләре катнаштылар. Алар дәүләт, төрле конфессияләр һәм төрле дин вәкилләре арасындагы элемтәләр хакында фикер алыштылар. Ахырдан резолюция кабул ителде. Анда төп пункт буларак динне сәясиләштерүдән качу, сәяси көрәшләргә динне һәм дини идеяләрне җәлеп итүдән тыелу карала.

МӨСЛИМӘЛӘР – ӨММӘТЕБЕЗ ТАЯНЫЧЫ

Казанда "Мөслимә. Бүгенге дөньяда кеше хокуклары" дип аталган фәнни-гамәли конференция узды. Әлеге чарада БМОның Кеше хокуклары буенча баш комиссары идарәсе вәкилләре, мөселман оешмалары лидерлары, депутатлар, дин әһелләре катнашты.

Конференция Хатын-кызларны кимсетүләрне юкка чыгару буенча БМО конвенциясенә 35 ел тулу уңаеннан үткәрелә. Чараның максаты - чит ил вәкилләрен Татарстан мөслимәләре эшчәнлеге белән якыннан таныштыру, бөтен дөньядагы мөселман хатын-кызларының хокукларын яклауга кагылышлы документлар турында сөйләшү.

Конференциянең пленар утырышында Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте аппараты җитәкчесе Ришат Хәмидуллин катнашты һәм Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин исеменнән чыгыш ясады: "Барчабызга мәгълүм, исламда хатын-кыз зур роль башкара. Корьәндә әйтелгән: " Үзегездән хатыннарны яралту да, ул хатыннар белән бергә яшәвегез дә, ир белән хатын арасындагы мәхәббәт һәм наз, бер-береңнең хаталарын кичерә белү, һичшиксез, Аллаһның кодрәтенә ачык дәлилләрдер. Хактыр ки, бу эшләрдә фикерли белүче кавемнәр өчен гыйбрәтләр бар" ("Рум" сүрәсе, 21 нче аять). Пәйгамбәребез (с.г.в.) үзенең бер хәдисендә әйтә: "Хатын-кызлар ир-атларның ярты өлеше". Димәк, хатын-кызларсыз ир-атлар да юк. Җирдә тормыш дәвам итсен өчен Аллаһы тәгалә хатын-кызларны яраткан. Аллаһы тәгалә хатын-кызларга максатчанлык, ныклык, актив булу сыйфатлары, оештыру сәләте биргән. Мөслимәләрнең республикабыз өммәте өчен тырышулары, уңышлы эшчәнлек алып барулары шуңа бер дәлил.

Бүгенге көндә мөслимәләр - җәмгыятьнең гыйлемле һәм социаль актив өлеше. Алар үз гаиләләре, ирләре, балалары өчен генә түгел, ә барлык мөселман өммәте өчен таяныч. Дини уку йортларында укучыларга карасак та, аларның күпчелеген хатын-кызлар тәшкил итә. Мөслимәләр динебез кыйммәтләрен балаларга гына түгел, өлкән яшьтәге ир-атларга да җиткерәләр. Бүгенге көндә ТР МДН карамагында мөселман хатын-кызларының Россия күләмендә эшләүче ике иҗтимагый оешмасы бар. Мөслимәләр тарафыннан хәйрия эшләренә зур игътибар бирелә. Без алга таба да, Алла кушып, республика мөслимәләренең күркәм йөзен булдыруга зур тырышлык куярбыз, аларга ярдәм күрсәтербез. Ә мөслимәләргә исә, үз ниятләрен тормышка ашыруларын телисе килә. Аллаһы тәгалә яхшы ниятләребезне һәм гамәлләребезне кабулларыдан кылсын!"

Берләшкән Милләтләр Оешмасының алда телгә алынган Конвенциясенә 185ләп ил кушылган. Ул - хатын-кызларның дәүләттә, җәмгыятьтә һәм гаиләдә ирләр белән тигез хокукка ия булуын тәэмин итү өчен дәүләт һәм иҗтимагый оешмаларның уртак эшчәнлек алып баруы максатын куя. Мөселман хатын-кызларының хокукларын яклау мәсьәләсенең көн кадагына чыгарылуына исә Европа илләрендә ислам динен тотучыларның саны арта баруы сәбәпче: алар хәзер икенче урында тора. Һәм, ничек кенә булмасын, хатын-кызларның хокукы белән исәпләшмәү күренешләре мөселман дөньясын да читләтеп узмый.

Мөселман хатын-кызларының хокукларын яклауга багышланган форумның күпмиллэтле Татарстанда үткәрелүе очраклы түгел. Республика социаль-икътисади яктан үсеш алган, иҗтимагый-сәяси тотрыклылык сакланган һәм төрле милләтләр, диннәр үзара килешеп, тынычлыкта гомер кичергән төбәк буларак билгеле. Соңгысы - әчке сәясәтнең мөһим өлеше булып, дәүләт һәм муниципаль хакимият органнарының аерым игътибарында тора. Статистика күрсәткәнчә, дәүләт идарәсендә җитәкче урыннарга хатын-кызларга юл ябык булган илләрдә халыкны социаль яклау мәсьәләләрен чишү дә шактый аксый. Ә Татарстанда вәзгыять башкача: дәүләт структураларында хезмәт куючы хезмәткәрләрнең 53,6 процентын хатын-кызлар тәшкил итә.

Хатын-кыз хокукларын яклау буенча халыкара документларны тикшерү, уңай тәҗрибәләрне барлау һәм фикер алышулар конференциянең икенче көнендә секция утырышларында дәвам итте.

"ГАБДЕЛХАК САМАТОВ – ТАТАРСТАН ӨММӘТЕН ДИНЛЕ ИТКӘН ХӘЗРӘТ"

Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте Россия ислам институты белән берлектә быел бишенче тапкыр "Саматов укулары"н уздырды. Конференция XX гасыр азагы - XXI гасыр башының күренекле дин әһеле Габделхак хәзрәт Саматовка багышланды.

Коръән укудан башланып киткән чара Татарстанның беренче казые, Мәрҗани мәчете имамы, галим Габделхак хәзрәт турындагы хатирәләрне яңарту һәм олуг шәхеснең мирасы турындагы чыгышлар белән үрелеп барды.

"Саматов укулары" на җыелган төрле төбәк дин әһелләрен, мөгаллимнәрне, югары дини уку йорты шәкертләрен Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин сәламләде. Ул Габделхак хәзрәтнең гыйлем таратудагы эшчәнлегенә аерым игътибар юнәлтте. Мөфти хәзрәт: "Бүген без бишенче мәртәбә "Саматов укулары"на җыелдык. Татарстанның беренче казые, мәгърифәтче, хикмәтле һәм зур гыйлемле Габделхак хәзрәт Саматов совет заманында динебезне саклап калган һәм аны үстергән, берничә буын дин әһелләрен тәрбияләгән олуг остаз. Габделхак хәзрәт кайда гына булмасын, халыкка дәрес биргән. Ул Татарстан өммәтен динле иткән хәзрәт", - диде.

Габделхак хәзрәт Советлар Союзы таркалгач, иң беренче булып рәсми мәдрәсә оештырган. Совет чорында, егерменче еллар уртасында Казанда ачылган беренче мәдрәсә Ислам динен кабул итүгә 1000 ел исемендәге мәдрәсә дип аталган була. Уку йорты озак вакытлар эшләмәгән. Туксанынчы елларда Габделхак хәзрәт тырышлыгы белән бу мәдрәсә халкыбызга кире кайтты. Хәзрәт башта Чистай шәһәрендә мәдрәсә ачты. Аннары Казанда Кабан арты мәчете бинасында - Ислам динен кабул итүгә 1000 ел исемендәге мәдрәсәне тарихи урынында эшләтеп җибәрде. Казанның "Мөхәммәдия" мәдрәсәсен ачуга да хәзрәтнең бик зур өлеш кертүе мәгълүм.

Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте ел саен остазлары юлын дәвам иткән хәзрәтләребезгә "Рухи мирас" бүләген тапшырып килә. Узган елларда әлеге олуг бүләк баш казый Җәлил хәзрәт Фазлыевка, Россия ислам институты ректоры Рәфыйк хәзрәт Мөхәммәтшинга, Габделхак хәзрәтнең улы Таһир хәзрәт Саматовка тапшырылган иде. Быел Татарстан мөфтие Камил хәзрәт бу зур бүләкне Габделхак хәзрәтнең шәкерте - Мәскәү һәм Чувашия мөфтие Әлбир хәзрәт Крганова тапшырды. "Олуг остазның бүләгән алуга аның рәхмәт сүзләрен ишеткән кебек булдым. Габделхак хәзрәткә 12 октябрьдә 84 яшь тулган булыр иде. Үзе артыннан ул бик уңдырышлы орлыклар чәчеп калдырды. Хәзрәт күрсәткән юлдан бара торган бик күп шәкерләребез бар һәм алар остаз юлын дәвам итәләр. Уфага укырга килгәч, имтихан алып утыручы Габделхак хәзрәт миңа: "Сине Казанга алабыз", - диде. Менә шулай итеп, Казанда аңардан берничә ел дәресләр алырга туры килде. Моннан 20 ел элек, 1994 елда үзе Чувашиягә килеп чираттагы бер корылтайда катнашты, анда мөфти сайланды. Әлеге корылтай да аның догасы белән үткән иде", - дип хатирәләрен яңартты Әлбир хәзрәт.

РИИ ректоры, мөфти урынбасары Рәфыйк хәзрәт Мөхәммәтшин, баш казый Җәлил хәзрәт Фазлыев һәм башка бик күпләр ихластан Габделхак хәзрәтне зурлаган сүзләрен җиткерделәр. Алар совет хакимияте елларында динебезне саклап калган муллаларның дин өчен, татар халкы өчен чын күңелдән тырышканлыклары турында сөйләделәр.

Чарада Габделхак хәзрәтнең юлын дәвам итүче уллары да катнашты. Ханты-Манси округы мөфтие Таһир хәзрәт Саматов, хатирәләрне барлаганнан соң, әтисенең эшен дәвам итүче шәкертләренә, менә шушы укуларны оештырган һәм Габделхак хәзрәтне зурлаган Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтенә, мөфти Камил хәзрәткә зур рәхмәтен белдерде.

ХАЛКЫБЫЗНЫҢ АСЫЛ КЫЗЫН ИСКӘ АЛДЫЛАР

Ислам динен кабул итүгә 1000 ел исемендәге Казан югары мөселман мәдрәсәсендә мөгаллимнәр, шәкертләр, җәмәгать эшлеклеләре катнашында халкыбызның асыл кызы Мәрьям(бикә) Солтанова-Акчуринаны искә алу чарасы булып узды. Ул Россия һәм Татарстан Мөселман хатын-кызлары оешмасы җитәкчесе Наилә ханым Җиһаншина һәм Акчуриннар нәселен өйрәнүгә күп өлеш керткән тарих фәннәре докторы Наил Таиров тырышлыгы белән оештырылды. Чара барлык төрки һәм ислам дөньясына таныш булган затның тууына 155 ел тулуга багышлана.

Галим Наил Таиров кичәдә катнашучыларны Мәрьям Солтанованың биографиясе белән таныштырды. Мәрьям Солтанова XIX гасырның икенче яртысы - XX гасыр башларында Сембер губернасы һәм барлык Идел буена билгеле фабрикант Тимербулат Акчуринның кызы. Заманында Казан кызлар гимназиясен тәмамлаган. Россия мөселманнары Диния нәзарәте башлыгы, мөфти Мөхәммәдьяр Солтановның улы Арслангалигә кияүгә чыкканнан соң, ул Уфада яши башлый. Мөселман хатын-кызлары җәмгыятен җитәкли.

Мәрьям Солтанова ятим мөселман һәм рус кызлары өчен балалар йорты, башлангыч мәктәп, мәдрәсәләр һәм китапханә ача. Ятим малайлар яшәгән балалар йортын һәм картлар йортын финанслый. Ул 1908 елда төзегән һәм җитәкләгән оешма мөселман хатын-кызларын иҗтимагый тормышка җәлеп итү, мәгърифәтчелек, хәйрия эшләре белән шөгыльләнә. Ире үлгәннән соң, Мәрьям Солтанова Уфадагы мөселман хатын-кызлары җәмгыяте эшләгән ике катлы бинаны ятим кызларга балалар йорты итеп бүләк итә. Уфаның Тукай урамында урнашкан ул йорт бүген дә исән. Йортка керү урынында, ишек кыегы астында әле һаман да "М" һәм "С" ягъни Мәрьям Солтанова исеменең баш хәрефләре саклана. Уфаның Мостай Кәрим урамындагы мәдрәсәсе дә аның исемен йөртә.

Мәрьям Солтанова - әтисенең игелекле эшләрен дәвам итүче. Наил Таиров сөйләгәнчә, заманында Акчуриннар мәктәпләр, мәдрәсәләр төзеп Сембер, Троицк, Уфа, Казан, Мәскәү, Петербург, Кырым һәм чит илләрдә сәләтле яшьләргә белем бирүне финанслаганнар. Сембер һәм Самарада мәчетләр төзеткәннәр. Петербург, Киев һәм Түбән Новгородтагы мәчетләр төзелешләренә дә ярдәм иткәннәр.

Тимербулат Акчурин Сембер Думасына да сайлана. Аның Гурьев шәһәрендә эшләгән сукно фабрикасы хәтта Россия хәрбиләренә шинель тегү өчен тукымалар җитештерә. 1881 елгы ачлыкта ул Уфа янындагы Иске Тимошкино авылында ярлылар өчен бушлай туклану ашханәсе ача. Анда көнендә 320 кеше туклана. Хәйрия эшчәнлеге өчен 1895 елда аңа "Тырышлык өчен" дигән алтын билге тапшырыла. Урыс-япон сугышы елларында ул яралыларны дәвалау өчен хастаханә ача. 1905 елда Иске Тимошкино авылында янгын чыгып, 240 йорт көл булганнан соң, аларга йортлар төзергә ярдәм итә. Фаҗигадә зыян күргән мең кешегә кием-салым, азык-төлек, утын, чәчү орлыклары һәм акча белән ярдәм итә.

Тимербулат Акчуринның улы Хәсән Акчурин татарда беренче музей оештыра. Анда гарәп, төрек, мисыр, барлык татар ханнары һәм мөселман дөньясында басылган акчалар туплана. Инкыйлабтан соң 1918 елда ул коллекцияне Сембер пролетар музеена тапшырган.

ЧАЛЛЫДА МӘЧЕТЛӘР АРТА

Чаллы шәһәрендә яңа мәчетләр төзү планлаштырыла. Шәһәр имам-мөхтәсибе Әлфәс хәзрәт Гайфуллин ошбу хакта болай дип белдерде: "Шәһәр киңәя бара. Яңа микрорайоннарда яшәүчеләргә хәзерге вакытта сафта булган мәчетләр ерагая. Шуңа күрә без шәһәр хакимиятенә яңа гыйбадәт йортлары төзелеше өчен җир участоклары сорап мөрәҗәгать иттек. Бүгенге көндә, Аллага шөкер, өч мәчет өчен җир алынды. Кайберсендә әкрен генә эш тә башланды. Шәһәр хакимиятенә мөселманнар ихтыяҗын аңлаулары, үтенечебезне кире какмаулары өчен рәхмәтләребезне белдерәбез."

Яңа мәчетләрнең берсе "Замелекесье" бистәсендә булачак. Биредә төзелеш өчен кирәкле барлык документлар булдырылган, мәхәллә юридик теркәү үткән, аның исәп-хисап счеты ачылган. Мәхәлләне оештыручыларның күпчелеге Чирмешән районының Утыз Имәни авылыннан булганга, аңа ошбу авылдан чыккан дин галимебез, шагыйрь Габдрәхим Утыз-Имәни исемен биргәннәр.

Мөхтәсибәт җитәкчеләре Орлов бөҗрасы янәшәсендәге кырда икенче бер мәчет төзелеше өчен җир участогы (24 сутый) чикләрен билгеләделәр. Ошбу изге эш дога кылудан башланды. Биредә төзеләчәк гыйбадәт йорты мөсафирлар өчен дә бик мөһим. Чөнки ул Казан - Уфа трассасы янәшәсендә (Казан проспекты) төзелергә тиеш.

Өченче мәчет өчен җир участогы Сидоровка бистәсенең "Сувар" шәхси хуҗалыклар районында алынган.

Мәгълүматлар dumrt.ru сайтыннан алынды

"Без мөэминнәрнең күңелләренә шифалы аятьләрне вә Коръәннән рәхмәтле хөкемнәрне иңдерәбез, әмма Коръән белән гамәл кылмаган залимнарга Коръән аятьләре хәсрәтне вә һәлакәтне генә арттырыр" ***("Исра", 82 нче аять).***

АЛЛАҺ ИЛЧЕСЕНЕҢ ДӘВАСЫ

Хөрмәтле һәм кадерле дин кардәшләрем, бу дәресебезне Аллаһы тәгалә Илчесе (с.г.в.) даруханәсенә багышларга булдык.

Ий, барлык пәйгамбәрләр Пәйгамбәре! Син дин белән бәйле авыруларны күрә беләсең һәм дәвалану өчен иң файдалы даруларны билгелисең. Без һәм бөтен дөнья сиңа бик рәхмәтле.

Кадерле кардәшләрем, нинди авырулардан нинди дарулар билгеләнгәнен беләсезме? Авыруларны санап карыйк: курку, проблемалар, стресслар һ.б. Тормышыбыз кайгылар һәм көчләү актлары, проблемалар һәм кыенлыклар белән тулы. Күрәсең, шуңа күрә Аллаһы тәгалә болай дип ант итә: **"Бу шәһәр, ягъни Мәккә белән ант итәмен. Вә син, ий, Мөхәммәд галәйһиссәләм, ошбу Мәккә шәһәрен кяферләрдән сугышып алырга хәләлсең. Вә Адәм галәйһиссәләм илә, вә аның балалары илә ант итәмен. Тәхкыйк, Без кешене михнәттә, мәшәкатьтә халык кылдык. Әллә ул михнәт белән изелгән зәгыйфь кеше уйлыйдырмы аңа һичбер затның көче җитмәс дип?** ***("Бәләде (Шәһәр" сүрәсе, 1-5 нче аятьләр).***

Хөрмәтле мөселманнар, кеше бу кыенлыклар белән тулы дөньяга аларны җиңәр өчен килә. Нәкъ менә шул сәбәпле бу проблемалар һәм кыенлыклар белән тулы дөнья "сынаулар дөньясы" дип атала да.

Бер тәкъва кешенең улы туа. Бу кеше елый башлый. Янәшәсендәге кешеләр аннан елавының сәбәбен сорыйлар: "Шатланыр урынга нигә елыйсың? Нинди бәхет! Синең улың туды..." Ул бу сүзләргә болай дип җавап кайтара: "Ул бүген үлде!" Дуслары аптырашып: "Бу ничек була инде? Ул әле генә туды бит", - диләр. Тәкъва кеше болай дип җавап кайтара: "Чөнки аның үлеме дә тууы кебек үк алдан ук билгеләнгән!"

Аллаһы тәгалә тарафыннан безгә билгеләнгән язмышта ике бит бар. Беренчесендә безнең туган көнебез язылган, икенчесендә - үләчәк көнебез. Димәк, төп шәҗәрәдә ике сүз, ике бит бар: туу һәм үлү. Бездән китеп, җеназа намазын укылу өчен алдыбызга куелган кешедән сорагыз: үлгәч, ул нәрсә күргән?

"Кеше, күпме генә яшәмәсен, барыбер үләчәк. Кешене кабергә илткәндә без үзебез дә Аллаһы тәгалә каршына барачагыбызны уйларга тиешбез. Аннан качыр урын юк".

Хөрмәтле кардәшләрем! Кыямәт көнендә "имтихан алучы комиссия" булачак. Без һәрвакыт бу дөньяда булган имтиханнардан куркабыз. Безгә алдагы бөек имтихан турында уйланырга кирәк! Бу имтиханда сорауларны укытучы бирмәячәк. Бу имтиханда сорауларны Аллаһы тәгалә бирәчәк: **"Кыямәт көне өчен Без гадел үлчәүне куярбыз, сабабы кимәтелеп яки гөнаһы арттырылып, һичкемгә золым итү булмас, гәрчә яхшылыгы гәрчич орлыгы хәтле генә булса да, аны үлчәүгә куярбыз. Хисап итеп җәза бирмәк өчен Мин җитәрмен!"** ***("Пәйгамбәрләр" сүрәсе, 47 нче аять).***

Алда телгә алынган комиссия турында менә бу аятьтә дә әйтелә: **"Ике язучы фәрештәне хәтергә төшер, берсе, уң тарафта утырып, изге гамәлләрне язар, вә берсе, сул тарафта утырып, гөнаһлы эшләрне язар. Сүз сөйләнмәс, мәгәр сөйләнгән һәрбер сүзне көтеп утыручы фәрештә язар"** ***("Каф сүрәсе, 17-18 нче аятьләр).***

Кадерле мөселманнар! Кайвакыт без куркыныч төшләр күрәбез. Бигрәк тә имтихан көннәрендә. Куркыныч төшләр күргән очракта безгә нәрсәләр эшләргә кирәк соң? Бу сорауга җавап табар өчен, Аллаһы тәгалә Илчесе (с.г.в.) даруханәсенә мөрәҗәгать итик: "Ий, Пәйгамбәр! Без куркыныч төшләр күргәндә, Син безгә нәрсә киңәш итә аласың?" Теләсә нинди авырудан дәва табуда булышучы булган Аллаһы тәгалә Илчесе (с.г.в.) болай ди: **"Матур һәм яхшы төшләр Аллаһы тәгаләдән, ә начарлары - шайтаннан. Кем дә булса начар төш күрсә, шайтан золымыннан Аллаһы тәгаләгә сыенсын һәм беркемгә дә төшен сөйләмәсен. Шулай эшләгән очракта шайтан берегезгә дә зыян китерә алмас".**

Фрейд алдында баш игән психологлар төшләрне Аллаһы тәгалә күрсәтмәләреннән ерак торган мәгънәләр биреп аңлаталар. Алар төшләрне йоклаучы кешенең ачыкланып җитмәгән уй-фикерләре нәтиҗәсе диләр. Шул ук вакытта Аллаһы тәгалә Илчесе (с.г.в.) безгә яхшы төшләрнең Аллаһы тәгаләдән булуы турында әйтте. Пәйгамбәребез (с.г.в.): "Миннән соң алдан күрүдән бары тик шатлык китерүче нәрсә генә калачак", - дигән. Сахәбәләр: "Нәрсә ул, ий, Аллаһы тәгалә Илчесе?" - дип сораганнар. "Яхшы төшләр", - дип җавап биргән Пәйгамбәр (с.г.в.).

Бервакыт Пәйгамбәребезнең хатыны Гайшә (радияллаһу ганһә) төшендә бүлмәсенә өч ай төшүен күрә. Бу төшен әтисе Әбү Бәкергә (радияллаһу ганһү) сөйләгәч, ул төшне болай аңлата: "Синең бүлмәңдә өч бөек кеше җирләнәчәк". Шулай итеп, билгеле булганча, бу төш чынга аша. Бу өч бөек кеше Аллаһы тәгалә Илчесе (с.г.в.) һәм мөхтәрәм Әбү Бәкер һәм Гомәр (радияллаһу ганһүмә) була. Чөнки алар өчесе дә Гайшә (радияллаһу ганһә) бүлмәсендә җирләнәләр.

"Матур һәм яхшы төшләр Аллаһы тәгаләдән" булуын онытмаска кирәк".

Бервакыт билгеле төш юраучы Мөхәммәд Ибне Сирин янына ике кеше килә. Аларның берсе мондый төш сөйли: "Мин төшемдә азан әйттем". Ибне Сирин бу кешенең йөзенә игътибар белән карагач, аның гөнаһка батканын күрә һәм төшен болай юрый: "Син - карак!"

Икенче кеше дә үзенең төштә азан әйткәнен күрү турында сөйли. Ибне Сирин аның йөзенә дә игътибар белән карый һәм болай дип юрый: "Аллаһы тәгалә теләсә, тиздән син хаҗ кылырсың!"

Моны ишетүчеләр аның бер үк төрле төшне төрлечә юравына гаҗәпләнәләр: "Ий, Ибне Сирин! Гаҗәп. Бу ике кеше бер үк төрле төш күрә. Ләкин Сез аларны төрлечә юрадыгыз. Беренчесенә аның карак булуын әйттегез, ә икенчесенә хаҗга китәчәген юрадыгыз. Бу ничек була инде?" Ибне Сирин болай дип җавап бирә: **"Аларның беренчесе - гөнаһлы кеше. Мин аның йөзенә карагач, менә бу аятьне исемә төшердем: "Агаларының нәрсәләрен хәзерләгәч, ягъни ашлыкларын үлчәп дөяләргә йөкләгәч, Йосыф Биняминнең йөгенә бер алтын савытны яшереп куйдырды вә шул хәлдә юлга чыгып киттеләр, соңра Йосыфның хезмәтчеләреннән берсе артларыннан барып: "Ий, кәрван кешеләре! Сез патшаның савытын урлагансыз", - дип кычкырды"** ***("Йосыф" сүрәсе, 70 нче аять).***

Ә икенче кешенең йөзенә карагач, мин аның гадел булуын күрдем һәм Аллаһы тәгаләнең сүзләрен искә төшердем: **"Кешеләрне хаҗга чакырып кычкыр, җәяү йөреп сиңа килерләр, вә арык дөяләргә атланып килерләр, ул дөяләр ерак юлларның һәрбереннән килерләр"** ***(Хаҗ" сүрәсе, 27 нче аять).***

Бервакыт Гомәр Ибне әл-Хаттаб (радияллаһу ганһү) янына бер кеше килеп төшен сөйли: "Бүген мин төшемдә ай белән кояшның көрәшүен күрдем". Мөхтәрәм Гомәр (радияллаһу ганһү): "Син кем яклы идең?" дип сорый. "Ий, Гомәр! Мин ай ягында, кояшка каршы идем", - дип җавап бирә. Гомәр (радияллаһу ганһү) аңа болай ди: "Син Аллаһы тәгаләне ачуландырган нәрсә эшләячәксең". "Ни сәбәпле?" - дип гаҗәпләнә кеше. Мөхтәрәм Гомәр (радияллаһу ганһү) түбәндәгечә җавап кайтара: "Чөнки Аллаһы тәгалә болай ди: **"Төнне вә көндезне ике галәмәт**

кылдык. Ай, йолдызлар - төн галәмәте, кояш - көн галәмәтедер, яки караңгылык - төн галәмәте, яктылык - көн галәмәтедер, төн галәмәте булган караңгылыкны җибәрәбез дә, көн галәмәте булган яктылыкны китерәбез, Раббыгызның юмартлыгыннан дөнья кирәкләрен кәсеп итмәклегегез өчен, дәхи ай, еллар хисабын белмәклегегез өчендер, вә һәрнәрсәне ачык бәян кылдык, игътибарлагыз!" ***("Исра" сүрәсе, 12 нче аять).***

Күп вакыт уза. Язид һәм мөхтәрәм Хөсәен (радияллаһу ганһү) арасында сугыш куба. Бу кеше Язид белән бергә мөхтәрәм Хөсәенгә (радияллаһу ганһү) каршы була. Шулай итеп, мөхтәрәм Гомәр (радияллаһу ганһү) юравы рас булып чыга.

Пәйгамбәребез (с.г.в.) сахәбәләре Аллаһы тәгалә Илчесеннән сорыйлар:

"Ий, Пәйгамбәр! Начар төш күргән очракларда безгә нәрсә эшләргә?" Ул болай дип җавап кайтара: "Җенси якынлык булган төш - шайтаннан". Кайчак кеше җенси якынлык булган төшләр күрә. Кайчак начар төшләр күрә. Бу төшләр шайтаннан. Кеше куркыныч яки начар төш күрсә, курыкмасын һәм кайгырмасын. Бу очракта бер яктан икенче якка борылып ятарга яки аякка басып болай дияргә кирәк: **"Мин каргалган шайтаннан Аллаһы тәгаләгә сыенам". Бу төш турында беркемгә дә сөйләмәгез. Шул очракта шайтан берни зыян китерә алмаячак".**

Кадерле һәм хөрмәтле кардәшләр! Йокысызлыктан булган дару турында берничә сүз әйтәсем килә. Күп очракта укучыларны имтихан алдыннан йокысызлык борчый башлый. Аларга йокысызлыктан ничек котылырга? Аллаһы тәгалә Илчесенең (с.г.в.) тормыш юлдашы мөхтәрәм Гайшә (радияллаһу ганһә) болай дип сөйли: **"Йокысызлыктан интеккән бер кеше, Аллаһы тәгалә Илчесе (с.г.в.) янына килеп, авыруыннан зарлана. Пәйгамбәр (с.г.в.) аңа мондый киңәш бирә: "Йокларга ятар алдыннан түбәндәге сүзләрне әйт: "Мин Аллаһы тәгаләгә Аның ачуыннан һәм шелтәсеннән, колларының золымыннан, шайтан коткысыннан һәм аларның миңа борчу китерүләреннән сыенам".** Бу дару - Аллаһы тәгалә Илчесе (с.г.в.) даруханәсеннән. Йокысызлыктан интеккән кеше бу даруны даими куллана башлый. Өч көннән бу кеше Пәйгамбәр (с.г.в.) янына килә дә: "Ий, Аллаһы тәгалә Илчесе! Аллаһы тәгалә минем борчуларымны юк итте. Йөрәгемнән курку китте, мин хәзер тыныч йоклыйм. Сине хакыйкать белән Җибрүче белән ант итәм, мин арыслан оясына керсәм дә курыкмаячакмын", - ди". Димәк, бу дога ярдәмендә бу кешенең йөрәгенә көч иңә, теле ныгый һәм Аллаһы тәгалә аның курку һәм кайгыларын юк итә...

Кадерле дин кардәшләрем! Шайтан коткылары һәм алардан саклаучы дарулар турында да сөйлисем килә. Без Аллаһы тәгалә Илчесе (с.г.в.) биргән даруларга бик мохтаҗ. Чөнки алар безгә иманыбызны ныгыту, җаныбызны һәм тәнебезне тынычландыру өчен кирәк.

Имам Мәлик (радияллаһу ганһү) үзенең "әл-Муватта" китабында тапшыра: "Аллаһы тәгалә Илчесенә (с.г.в.) намаз кылганда комачаулар өчен аның тарафына таулардан һәм далалардан шайтаннар юнәлә. Аллаһы тәгалә Илчесенә (с.г.в.) нинди булса да зыян китерер өчен барысын да эшләгәч, Җәбраил (галәйһиссәләм) килеп, болай ди: "Ий, Аллаһы тәгалә Илчесе! Менә бу доганы укы: **"Ий, Рәхимле һәм Шәфкатьле Аллаһ! Тәнемә зыян китерүчедән, күктән төшүче һәм күкләргә күтәрелүченең золымыннан, көн һәм төн коткысыннан, төнлә яманлык кылу өчен килүчеләрнең явызлыгыннан яклавыңны үтенәм!"** Менә бу доганы шайтан хәйләләренә каршы укырга кирәк. Сихерчеләргә һәм күрәзәчеләргә барырга кирәкми. Чөнки аларга барган һәм аларның сүзләренә ышанган кеше, үзенең Аллаһы тәгалә Илчесе (с.г.в.) аша иңдерелгән Коръәни-Кәримгә каршы баруын белсен. Күрәзәчеләр сүзләренә ышанмаса да, барыбер аларга барган кешенең намазын Аллаһы тәгалә 40 көн буе кабул итмәс.

Кадерле дин кардәшләрем! Без бу хакыйкатьләрне һәм ислам даруларын сезгә, аларны кулланып, рухи яктан дәвалануыгыз өчен тәкъдим иттек.

Бозык җәмгыятьтә яшәвебезне онытмаска кирәк. Бөтен яхшы һәм матур төшенчәләр алмашынды. Яхшылары начар, ә начарлары яхшы итеп күрсәтелә башлады. Кайбер массакүләм мәгълүмат чаралары үз эшчәнлекләрен дин һәм әхлакны бозуга багышлый. Фән исеменнән булган басмалар динне юк итәргә тырыша. Күпчелек фильмнар, телевидение тапшырулары, спектакльләр һәм көндәлек газеталар көн саен исламга һөҗүм ясыйлар, мөселманнарны тәнкыйтьлиләр һәм мыскыл итәләр. Исламга каршы сугыш башлаган бу чараларда һәм басмаларда Аллаһы тәгалә исемен кемнең дә булса үлүе һәм үтерелүе сәбәпле генә искә алалар. Шуңа күрә без Аллаһы тәгалә Илчесе (с.г.в.) тәкъдим иткән даруларга бик мохтаҗ. Начар төшләрдән һәм дингә каршы, динне җимерүгә юнәлтелгән күренешләрдән без Аллаһы тәгаләдә яклау эзләргә тиеш. Күңел төшенкелеге, тынычсыз тормыш кичергәндә безгә Аллаһы тәгалә Илчесе (с.г.в.) тәкъдим иткән рухи даруларны кулланырга кирәк: **"Ий, Рәхимле һәм Шәфкатьле Аллаһ! Тәнемә зыян китерүчедән, күктән төшүче һәм күкләргә күтәрелүченең золымыннан, көн һәм төн коткысыннан, төнлә яманлык кылу өчен килүчеләрнең явызлыгыннан яклавыңны үтенәм!"**

Ий, җаннарны дәвалаучы! Бу яхшы даруларны тәкъдим итүеңә без чиксез рәхмәтле. Аллаһы тәгаләнең сәламе һәм рәхмәте сиңа, гаиләңә, сахәбәләреңә һәм синең юлыңнан баручыларга ирешсен иде.

Әссәләәму галәйкүм үә рахмәтүллаһи үә бәракәтүһ!

ШАЙТАН КЕШЕЛӘР АРАСЫН БОЗА АЛАМЫ?

Кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләрне бозу - шайтанның күңел түрендәге теләкләренең берсе. Үзенең максатына ирешү өчен ул барлык чараларын да эшкә җигәргә әзер. Аның бар көче, адәм балалары арасына вәсвәсә кертеп, дошманлык һәм ызгыш-талаш орлыкларын чәчүгә сарыф ителә.

Дошманлык хисе, аңлашылмаучанлык, бер-береңә әйткәннәрне ялгыш аңлау булмасын һәм шулай ук шайтан үз максатына ирешмәсен өчен, Аллаһы тәгалә кешеләргә түбәндәге аятьне иңдергән: **"Бәндәләремә әйт, иң татлы сүзләр генә сөйләсеннәр. Чөнки шайтан аларның арасында гауга чыгаручы. Һичшиксез, шайтан - кешенең иң хәтәр дошманы"** ***("Исра" сүрәсе, 53 нче аять).***

Шайтан һәм аның ярдәмчеләре вәсвәсә салып, кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләрдә дорфалык һәм тупаслык барлыкка килә, чөнки дорфалык һәм тупаслык барлык мөнәсәбәтләрне ачыклау, ислам диненең нигезе булып тора торган ярату, ихтирам һәм үзара аңлашу хисләрен бетереп, дошманлык тудыра. Пәйгамбәрләрдән Йосыф галәйһиссәләмнең агалары шайтан котыртуы аркасында аны коега салырга уйлыйлар. Безгә Кәламе шәриф бу турыда болай ди: **"Ата-анасын ул абруй тәхетенә утыртты, кавышу сөенеченнән аларның барысы да (Йосыфның шәһрәте алдында) баш иде, намаз укыды. Йосыф:**

- Ий атакаем, менә бу эшләр әллә кайчан күргән төшемнең юралуы булыр, - диде. - Раббым аны, ниһаять, тормышка ашырды. Дөрес шул: Аллаһ миңа рәхмәтен яудырды. Мине зинданнан чыгарды. Кардәшләрем белән минем араны шайтан бозганнан соң, сезне чүл аша имин чыгарды. Шик юктыр ки, Раббым ихтыяр иткән колына мәрхәмәтле. Хактыр ки, Аллаһ - барысын да белеп торучы хикмәт иясе" ***("Йосыф" сүрәсе, 100 нче аять).***

Җәбирнең (р.г.) риваять кылуы буенча, Аллаһ Илчесе (с.г.в.) әйткән: "Кемдер Гарәбстанда хәзер аңа гыйбадәт кылачагына шайтан ышанычын югалтты. Әмма ул мөселманнар арасында дошманлык салу өчен бар көчен куячак" (Мөслим, Сыйфателкыямә: 17, №7281, 8/138).

ШАЙТАННЫҢ НАМАЗ УКУЧЫГА КОМАЧАУЛАВЫ

Шайтан һәм аңа ярдәм итүче җеннәр, төрле чит уйларны (вәсвәсә) күп итеп җибәреп, намаз укыганда кешегә комачауларга тырыша. Әбү Һурайрадан (р.г.) тапшырылган хәдистә Аллаһ Илчесе (с.г.в.) әйткән: "Азан әйткәндә шайтан кача. Әйтеп бетергәч, янә барлыкка килә. Намазга камәт әйтә башласалар, ул тагын югала. Камәт әйтелеп беткәч, кеше һәм аның нәфесе арасына кереп утырып, янә килеп чыга: "Моны исеңә төшер, тегене исеңә төшер", - дип әйтеп, барысын да рәттән аның исенә төшерә. Шул вакытка кадәр ки, кайчан кеше ничә ракәгать намаз укыганын онытмый" (Бохари. Салят: 28/6, №1174, 1/413).

Раббыбыз безне шайтан вәсвәсәсеннән сакласа һәм гыйбадәтләребезне ихлас күңелдән үтәүне насыйп кылса иде.



ҖЕННӘР КҮКЛӘРДӘГЕ БЕЛЕМНЕ УРЛЫЙМЫ?

Аллаһ Илчесе (с.г.в.) җир йөзенә килгәнчегә кадәр җеннәр күкләрдә фәрештәләр бер-берсенә хәбәр итә торган яңалыкларны тыңлаган. Гайшә (р.г.) җиткергәнчә, Пәйгамбәр (с.г.в.) түбәндәгеләрне сөйләгән: "Фәрештәләр Гананда (болытта) җыелган хәлдә җирдә булырга тиешле хәлләр турында фикер алыша. Шайтан бу вакытта моны ишетеп, аны ялган белән кушып, савыттан су койган кебек күрәзәчеләрнең колагына җиткерә" (Бохари, Бәдел-хак: 11, №3114, 3/1197).

Коръәни-Кәримдә бу турыда түбәндәгеләр әйтелгән: **"Хактыр ки, без (җеннәр) Күккә менәргә (Аллаһ белән фәрештәләрнең сөйләшкәнен тыңларга) тырышып карадык. Ләкин Күкнең хәтәр сакчылар-каравылчылар белән һәм атыла торган утлы йолдызлар белән тулганлыгын күрдек. Яшеренеп тыңлар өчен без (Күкнең) уңай почмакларына постык. Ләкин тыңларга теләгәнне анда ут чыбыркысы сагалап тора икән"** ***("Җен" сүрәсе, 8-9 нчы аятьләр).***

Икенче бер сүрәнең түбәндәге аятендә болай диелә: *"Хактыр ки, Без иң якын Күкне зиннәтле йолдызлар белән бизәп куйдык. Шулай итеп, Без аны (Күкне) итагатьтән чыккан һәр шайтаннан сакладык. Алар (шайтаннар) күкләрдә киңәшүче фәрештәләрнең сүзләрен ишетеп тормасын өчен (йолдыз ташлары белән атылып) куылды. Алар озакка сузылган газапка дучар булачак. Мәгәр ки, (шайтаннарның) берәрсе берәр сер эләктереп кача башласа, аны бер чаткы (атылган йолдыз) эзәрләкләячәк"* ("Саффат" сүрәсе 6-10 нчы аятьләр).

Татарстан мөфтие
Камил хәзрәт СӘМИГУЛЛИН

МӨГАЛЛИМНӘР МӘХӘЛЛӘНЕ ТӘРБИЯЛИ

Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте Россия ислам институты һәм Казан (Идел буе) федераль университеты белән берлектә "Ислам мәгарифен камилләштерү ысуллары" дип аталган укулар оештырды. Әлеге чарага тәҗрибә уртаклашу һәм өстәмә гыйлем туплау ниятеннән республика мәчетләрендә башлангыч дини белем бирүче 3000 гә якын мөгаллимә килде. Анда республика дин әһелләре һәм мөгаллимнәреннән тыш Төркиядән килгән мөхтәрәм кунаклар дә катнашуы төрле иллӛрдәге мәгариф юнәлешләрен күзалларга ярдәм итте.

Укулар мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллинның аһәңле итеп Коръән укуы һәм мөгаллимнәрне сәламләве белән башланып китте. "Бик күпләр дин гыйлемен иң беренче чиратта мәчет каршында оештырылган курсларда укып ала. Мөгаллимнәр мәхәлләне тәрбияли. Мәхәллә халкының иманын ныгыта. Динебезгә гыйлем аша гына төгәл, дөрес итеп чакырырга мөмкин. Менә шуның өчен дә дини мәгариф системасы - Диния нәзарәтенең иң мөһим өлкәсе булып тора. Аллага шөкер, бүгенге көндә республикабызда 1500 гә якын мәчет эшләп килә һәм шулар каршында 800 дән артык мөгаллим башлангыч дини белем бирә, - дип, Камил хәзрәт мөгаллимнәргә үзенең рәхмәтләрен дә ирештерде. - Пәйгамбәребез бер хәдисендә әйткән: "Ике кешегә гали дәрәҗәләр бирелер: берсе - Аллаһның биргән малларын хак юлда сарыф иткән бай кешегә; икенчесе - Аллаһның биргән гыйлемен башкаларга өйрәткән һәм араларында гыйльми фикерләр биргән галимгә". Менә шушы җыелыштан файдаланып, нәзарәт һәм үз исемемнән сезгә шушы мәртәбәле, дәрәҗәле хезмәтегез өчен рәхмәтләремне әйтәсем килә. Аллаһы тәгаләнең рәхим- шәфкатьләре, бәрәкәтләре язсын".

Чарада катнашкан мөфтинең дини мәгариф юнәлешенә җаваплы урынбасары, Россия ислам институты ректоры, профессор Рәфыйк Мөхәммәтшин үз чыгышында мәчетләр каршында оештырылган укытуларның әһәмиятен елдан-ел аңлый баруыбыз хакында әйтте. "Якынча исәпләүләргә карганда, курсларда 30 меңгә якын кеше башлангыч дини белем ала. Алар арасында яшьләр дә, картлар да бар. Сезнең аларны дини яктан тәрбияләүдә өлешегез зур. Нәзарәт, РИИ тарафыннан да мөгаллимнәргә игътибар зур булырга тиеш. Шуны аңлап, шушындый курслар оештырабыз да һәм нәшер ителгән дәреслекләр өләшәбез. Бергә җыелышып сөйләшү вакытында сорауларны ачыклап, тәкъдимнәр хакында да киңәшәбез", - диде ул.

Мөгаллимнәр каршында Төркиядән килгән кунаклар - Төркиянең дини эшләр идарәсенең мәгариф департаменты җитәкчесе, доктор, профессор Али Эрбаш һәм Төркиянең Мәскәүдәге илчесенең дини эшләр буенча киңәшчесе Дурсын Әйгүн чыгыш ясады. Алар Төркиянең дини мәгариф өлкәсе белән таныштырдылар һәм белем бирү өлкәсендә үзара хезмәттәшлеккә чакырдылар. Чит ил кунаклары Төркия мәдрәсәләрендә миллион ярым шәкерт белем алуы хакында әйттеләр. Төркиянең дини идарәсе карамагында гына да 24 мең мәдрәсә эшли, ә җәй көннәрендә мәчетләрдә оештырылган 2 айлык укуларга 4 миллионнан артык шәкерт җыела икән.

Укуларда шулай ук мәгариф турындагы яңа канунда дини уку-укыту учреждениеләренә кагылышлы үзенчәлекләр хакында да сөйләнде. Бу хакта РФ Мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек итү федераль хезмәте эксперты Рөстәм Хәйбрахманов җентекләп аңлатты. Татарстан Фәннәр академиясе өлкән фәнни хезмәткәре Камил Насыйбуллов мәчетләр каршында оештырылган курсларга кагылышлы мониторинг нәтиҗәләре белән таныштырды. "Мәчетләр каршында оештырылган курсларның һәм мәдрәсәләрнең иң зур үзенчәлеге шунда - аларда һәр укучыга индивидуаль- шәхси якын килү бар. Программаларда менә шушы үзенчәлек искә алына",- дип билгеләп узды ул.

Россия ислам институты мөгаллиме Габдулла хәзрәт Әдһәмов "Гакыйдә дәресен укытуның актуаль проблемалары" дигән темага тукталды. "Гакыйдә дәресен укытканда иң актуаль мәсьәлә ул - идеология. Безнен бабаларыбыз ислам динен кабул иткән көннән башлап, үзләренең дини юлларын хәнәфи мәзһәбе буенча алып барганнар. Әмма, кызганыч, совет чорында безнең бу традиция өзелеп торды. Узган гасырның 80-90 нчы еллары башында динебез яңадан уянып килгәндә безнең җирлеккә чит агымнар да керә башлады. Хәзер безнең өчен үзебезнең тамырларыбызга кайту мөһим. Аның өчен без, әлбәттә, үткәнебез белән таныш булырга тиеш", - диде Габдулла хәзрәт. Сүзен дәвам итеп, хәзрәт ислам фәннәренең барлыкка килүе һәм үсеше, гакыйдә фәнендә хәнәфи мәзһәбенең дөнья буенча таралуы хакында сөйләде.

Чара кысаларында республиканың төрле район мөхтәсибәтләренең дини уку-укытуны оештыру тәҗрибәләре белән мөгаллимнәр үзләре таныштырдылар. Бу уңайдан Кукмара мөхтәсибәтенең үрнәк тәҗрибәсе күпләрдә кызыксыну уятты.

Мөгаллимнәр җыелышын мөфти урынбасары Рөстәм хәзрәт Хәйруллин алып барды. Хәзрәт дистә еллар дәвамында халкыбызга динебезне җиткерүче, барлык тырышлыкларын куеп дингә хезмәт итүче мөхтәрәм мөгаллимнәргә Аллаһы тәгаләнең әҗер-савапларын теләде. Мөхтәсибләрнең мәчетләр каршында укулар оештыруга зур игътибар бирүләрен һәм авылларда башлангыч дини белем алуның бик зур әһәмияткә ия булуын ассызыклады.

Айзирәк ГӘРӘЕВА,
ТҖ МДНнең матбугат хезмәте баш белгече

ӨММӘТКӘ КҮП ФАЙДА ӨМЕТ ИТӘБЕЗ



Мәчетләребез каршындагы курсларда укытучы мөгаллимнәрнең уку елы алдыннан очрашып киңәшләшеп, тәҗрибә уртаклашып алулары күркәм бер традициягә әйләнеп бара.

Баштагы елларда укытучылар күбрәк үзләре сөйлиләр иде. Узган ел без аның форматын бераз үзгәртеп, семинар рәвешендә үткәрә башладык. Чөнки бу бит әле мөгаллимнәребез өчен квалификация күтәрү чарасы да булып тора. Төп фәннәрне укыту алымнары, методикасы буенча нинди кыенлыклар белән очрашалар, башлыча, шушы мәсьәләләрне күтәрәбез. Семинар барышында лекцияләрне тәҗрибәле мөгаллимнәр, Россия ислам институты, "Мөхәммәдия" югары мәдрәсәсе укытучылары укый. Әдәбият белән дә ярдәм итәргә тырышабыз, дәреслекләр, уку ярдәмлекләре әзерлибез. Быел мөгаллимнәргә Камил хәзрәт Вәлиуллинның ике дәреслеге - "Ислам тәрбиясе" һәм "Ислам тәрбиясе дәресләрен укыту методлары" дигән китаплар таратылды. Моннан тыш Диния нәзарәтенең фән һәм мәгариф бүлеге тарафыннан әзерләнгән, Голәмәләр шурасы хуплавы белән нәшер ителгән "Мәчетләр каршындагы курслар өчен укыту программасы" өләшенде. Дөрес, курсларга йөрүче балалар саны әлегә азрак, 10-15 процент кына. Шулай булса да, алар белән эшләү методикасын булдыру, махсус дәреслекләр бик кирәк иде. Быел без нәкъ менә балалар белән эшләүгә күбрәк игътибар итүне максат итеп куйдык.

Алга таба планнар бик зурдан. Районнарда булырмы ул, берничә районны берләштерепме, мөгаллимнәр өчен даими нигездә эшли торган квалификация күтәрү курслары ачарга ниятлибез. Методик әсбаплар, дәреслекләр белән ярдәм итүне дәвам итәргә, башлангыч курсларга атап үзенчәлекле серия чыгарырга да исәп бар.

Мәчет каршындагы бу курсларның мөһимлеге турында үз чыгышында мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллин да әйтеп узды. Моны куәтләп шундый дәлил китерәм: безнең мәдрәсәләрдә 3 меңнән артык кеше укыса, курсларда 4-5 тапкыр күбрәк, бәлки бу сан 30 меңләптер. Төп-төгәл санын әйтү кыен, чөнки аларның бер өлеше килә, китә, ташлый, кабат башлый. Бу курсларны, чын мәгънәсендә, халык мәгарифе дип атарга була. Аларда яшьләр дә, өлкән яшьтәгеләр дә, балалар да белем ала, ислам дине белән танышуны күпчелеге шуннан башлый. Әгәр дә аңа күбрәк игътибар биреп, сыйфатын тиешле дәрәҗәгә күтәрсәк, бу куәтле инструмент өммәтебезгә күп файда китерәчәк.

Айдар КАРИБУЛЛИН,
ТҖ МДНнең
фән һәм мәгариф
бүлеге мөдире

КИТАПЛАРГА ЫШАНУ

АЛЛАҺЫ тәгалә пәйгамбәрләр аша кешеләрне бер Аллаһыга ышанырга, Аңа гына табынырга һәм Аңа тиңдәшләр уйлап тапмаска өйрәтә торган Изге Китаплар җибәргән. Барлык пәйгамбәрләр дә Раббыбыздан алган хәбәрләрне кешеләргә тулысынча, бернинди үзгәрешләрсез, өстәмәләрсез яки кыскартуларсыз җиткерәләр, аңлаталар һәм үзләре дә шуларны үти торган булалар. Һәр Китапта да бер Аллаһыга гына табынырга өндәү, Аллаһы тәгалә турында белемнәр, һәр тарихи чор өчен яраклы үзенчәлекле боерыклар һәм тыюлар бирелгән, кешеләргә бу дөньяда һәм үлгәннән соң бәхеткә ирешү юллары өйрәтелгән була. Яңа Китап аннан алдагысында язылган кануннарны юкка чыгара алган.

Кайсыбер пәйгамбәрләргә аерым битләр (төргәкләр) җибәрелгән. Мәсәлән, Аллаһы тәгалә Адәм галәйһиссәлләмгә Изге Китаптан 10 бит, Шис галәйһиссәлләмгә - 50 бит, Идрис галәйһиссәлләмгә - 30 бит, ә Ибраһим галәйһиссәлләмгә 10 бит җибәрә.

Кешеләргә төрле чорларда дүрт китап җибәрелүе мәгълүм:

1. Тәүрат (Тора) Муса (Моисей) галәйһиссәлләмгә җибәрелә.

2. Забур (Псалтырь) Дауд (Давид) галәйһиссәлләмгә җибәрелә.

3. Инҗил (Евангелие) Гайсә (Иисус) галәйһиссәлләмгә җибәрелә.

4. Коръәни-Кәрим Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи үә сәлләмгә җибәрелгән.

Кайсыбер Изге Китаплар аерым халыклар һәм кабиләләргә җибәрелә. Ә Коръәни-Кәримдә язылганнар Кыямәт көненә кадәр барлык кешеләргә дә юнәлдерелгән. Мөселманнар Аллаһы тәгалә җибәргән барлык Китапларга да (аларның беренчел рәвешендә) ышанырга тиеш. Ләкин бүгенге көндәге Тәүрат һәм Инҗил китапларының вариантларына ышанып гамәл кыла алмыйбыз. Чөнки Коръәни-Кәримнән башка китаплар вакытлар узган саен төрле сәбәпләр белән үзгәреш кичергәннәр һәм хәзер аларда чын-чынлап Аллаһы тәгаләнең Изге Сүзләре асыл, төп мәгънәсендә инде сакланмаган.

КОРЪӘНИ-КӘРИМ

Коръәни-Кәрим - Аллаһы тәгаләнең пәйгамбәрләр аша кешеләргә җибәргән соңгы Китабы. Мөселманнар Коръәни-Кәримдә Аллаһы тәгаләнең хак Сүзләре булуына ышаналар.

Коръәни-Кәрим Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи үә сәлләмгә аз-азлап 23 ел дәвамында иңдерелгән. Тарихта Аллаһы Илчесенең (салләллаһу галәйһи үә сәлләм) авызыннан Коръәни-Кәримне ким дигәндә җиде кешенең тулаем яттан өйрәнүе билгеле.

Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи үә сәлләм үлгәндә, Коръәни-Кәрим өлешләп пальма сүсенә, сөякләргә һәм шул вакытларда кулланылышта йөргән башка материалларга язылган була. Мөселманнарның хөкемдары булып гадел Әбү Бәкер (Аллаһы аннан разый булса иде) хәлифә кала. Торабара хәлифә Коръәнне бер төргәк итеп җыярга карар кыла. Шул рәвешле Коръәни-Кәримнең беренче тулы язмасы барлыкка килә.

Коръәни-Кәрим гарәп телендә иңдерелгән. Ул 114 сүрәдән (өлештән/бүлектән) гыйбарәт. Һәр сүрә аятьләргә (аерым юлларга) бүленә.

Коръәнне яттан өйрәнүе бик җиңел һәм бу - Аллаһы тәгаләнең мөселманнарга бүләк иткән могҗизаларыннан берсе. Дөньядагы мөселманнарның күбесе гарәп булмаса да, Коръән уку кагыйдәләренә өйрәнеп, тиз арада аны баштан ахыргача ятлап чыгалар. Коръәни-Кәримне тулысынча яттан өйрәнеп, күңелендә саклаган кеше "хафиз" дигән гарәп сүзе белән атап йөртелә. Аллаһыга шөкер, мөселманнар арасында һәрвакытта да Коръәни-Кәримне йөрәгендә саклаган кешеләр булган һәм хәзер дә бар.

Ел саен Рамазан аенда Коръәни-Кәрим тәравих намазында баштан ахыргача тулаем укып чыгыла. Моның мәгънәсе бик тирән: 14 гасырдан бирле бөтендөнья мөселманнары һәр мәзһәбтә ел саен Коръәнне тулысынча кабатлыйлар. Аллаһы тәгалә шул рәвешле Коръәни-Кәримне үзгәрешләрдән саклый. Кыямәт көненә кадәр Коръәннең үзгәрешсез калуын Раббыбыз вәгъдә иткән һәм Ул үз вәгъдәсен бозмый.

"Дөреслектә, Без Коръәнне Үзебез иңдердек һәм үзгәрүдән аны Үзебез сакларбыз" ("Әл-Хиҗер" сүрәсе, 9 нчы аять).

"Ислам турында сөйләшик" энциклопедиясеннән

"АЛАР КОРЪӘН УКЫЙ, Ә КОРЪӘН АЛАРГА ЛӘГЪНӘТ УКЫЙ"

ӘНӘС Ибне Малик (Аллаһы тәгалә аннан разый булса иде) болай дигән: **"Бар шундый кешеләр: алар Коръән укый, ә Коръән аларга ләгънәт укый"**. Алар - Коръәнне игътибар белән укымаган һәм тәҗвид кагыйдәләрен үтәмәгән кешеләр.

Борынгы заманның бөек кешеләре болай дигән: ниндидер бер Аллаһ колы Кәламе шәрифне ачып, аның сүрәләрен укыса, ул аны укып бетергәнгә кадәр фәрештәләр аның өчен дога кылып тора. Икенче бер Аллаһ колы да Коръән сүрәсен укый, ә фәрештәләр аңа ләгънәт әйтә. Әлеге бөек кешеләрдән: "Бу ничек болай була соң?" - дип сораганнар. Алар: "Әгәр дә кеше Коръән сүрәсе укып, анда рөхсәт ителгәннәрне "рөхсәт ителгәннәр" дип, ә тыелганнарны "тыелганнар" дип кабул итсә, фәрештәләр аның өчен дога укыячак. Киресенчә булган очракта алар аңа ләгънәт укыячак", - дигән.

Без шуны гына өстәп әйтә алабыз: әгәр кем дә булса Коръәни-Кәримнең мәгънәсен аңлый алмаса, анда рөхсәт ителгәннәрне - "рөхсәт ителгәннәр", ә тыелганнарны "тыелганнар" дип кабул итсә, фәрештәләр аның өчен барыбер дога укыячак. Әгәр дә инде ул гарәп телен дә белеп, Коръәннең мәгънәсен дә аңлый алса, бу - Коръән мәгънәсен аңлый алмаудан күпкә бөегрәк булачак.

Кайбер галимнәр әйткән: "Бер Аллаһ колы Коръән укыр, һәм үзе дә белмичә, ләгънәткә дучар булыр". Бу шул рәвешле килеп чыгарга мөмкин. Мәсәлән, ул "Җәберләүчеләргә Аллаһның ләгънәте төшсен!" аятен укыса һәм ул үзе дә башка кешеләрне җәберләсә, аңа Аллаһның ләгънәте төшәчәк. Яисә ул "Алдакчыларга Аллаһның ләгънәте төшсен!" аятен укыса, һәм ул үзе дә алдакчы булса, аңа да Аллаһның ләгънәте төшәчәк. Майсаратуль-Ашчаи болай дигән: **"Начар кешедә Коръән - чит ил кешесе"**.

Әнәс Ибне Малик (Аллаһы тәгалә аннан разый булса иде) Пәйгамбәребезнең (аңа Аллаһның рәхмәте вә сәламе булса иде) түбәндәге сүзләрен җиткерә: "**Тәмугның карап торучылары потка һәм утка табынучыларны җәзага тартачак, ләкин алар: "Белгән кеше бервакытта да үзен надан кебек тотмас"**, **- дия-дия, Коръән укыган бозык кешеләрне тагын да ныграк җәзага тартачак".**

Бу монафикълык гамәле буенча галимнәрнең кайберләре бүтән фикердә тора. Аларның берише моны "дин буенча монафикълык" дисә, кайберләре - "гамәл белән башкарылган монафикълык"ка кертә.

Әбү Сәгид (Аллаһы тәгалә аннан разый булса иде) Пәйгамбәребезнең (аңа Аллаһның рәхмәте вә сәламе булса иде) түбәндәге сүзләрен җиткерә: **"Ул сиңа гөнаһлар эшләр өчен киртәгә әйләнерлек булганчы, Коръәнне укы! Әгәр дә моның киресе булган очракта, син - Коръән укучы була алмыйсың".** Ягъни, әгәр кем дә булса Коръәнне укып, аның хөкемнәренә тәкълид итмәсә, ул аннан файда ала алмый. Димәк, ул сиңа каршы шаһитлык итәчәк, синең дошманың булачак.

Сүхәйб (Аллаһы тәгалә аннан разый булса иде) Пәйгамбәребезнең (аңа Аллаһның рәхмәте вә сәламе булса иде) түбәндәге сүзләрен җиткерә: **"Коръәндә тыелган әйберләрне "рөхсәт ителгән" дип кабул итүче - аңа инанган була алмый".**

Гүкъбә Ибне Әмир (Аллаһы тәгалә аннан разый булса иде) Пәйгамбәребезнең (аңа Аллаһның рәхмәте вә сәламе булса иде) түбәндәге сүзләрен җиткерә: "Минем өммәтемдәге монафикъларның күпчелеге - Коръән укучы кешеләр".

Әнәс (Аллаһы тәгалә аннан разый булса иде) тапшырганча, Пәйгамбәребез (аңа Аллаһның рәхмәте вә сәламе булса иде) әйткән: **"Миңа үз өммәтемә бирeләчәк савапларны күрсәттеләр. Алар арасында кемнәрнең дә булса мәчеттәге чүпне чыгарып ташлаганнары өчен бирелгән савап та бар иде. Миңа шулай ук өммәтем кылган гөнаһларны да күрсәттеләр, мин исә алар арасында Коръәннең кайсы да булса берәр сүрәсен өйрәнеп, аннары аны оныткан өчен бирелгән гөнаһтан да зуррагын күрмәдем".**

Галимнәр: **"Әгәр кем дә булса Коръәнне аһәңле (матур) итеп укырга теләмәсә - ул аның кадерен белми дигән сүз, димәк, аңа әһәмият бирми, ә бу исә - аның каты җәза алуына сәбәп булачак",** - ди.

Сәгед Ибне Гүбәдә (Аллаһы тәгалә аннан разый булса иде) Пәйгамбәребезнең (аңа Аллаһның рәхмәте вә сәламе булса иде) түбәндәге сүзләрен җиткерә: **"Әгәр бер кеше Коръән укый белсә һәм аннары аны укудан туктаса яисә белгәнен онытса, Кыямәт көнендә ул тиресе бозылган хәлдә Аллаһ каршына басар".**

ISLAM-TODAY

ИРТӘНГЕ НАМАЗНЫ УКУ ӨЧЕН ИҢ ЯХШЫ ВАКЫТ

ИРТӘНГЕ намаз "Фәҗер"нең башы - "икенче фәҗер" барлыкка килү вакыты, ягъни икенче таң яктылыгы. Ул исә кояш чыгу белән бетә. Иртәнге намаз өчен иң яхшы вакыт - аның вакытының ахыргы өлешенә туры килгән "исфар" вакыты (ул яктылык яхшы беленгән чак, ягъни кояш чыгарга 20-30 минут калган вакыт). Аллаһның Рәсүле болай дигән: "Иртәнге намазны яктылык беленгәч укыгыз, чөнки намазны бу вакытта үтәгән өчен әҗер күбрәк".

Галәветдин Сәмәркандиның "Төхфәтел-Фукаһа" китабыннан

ДӘҖҖАЛ ФЕТНӘСЕННӘН САКЛАНУ ДОГАСЫ

АЛЛАҺ Рәсүленең (с.г.в.) дәвамлы укыган бер догасы: **"Аллаһүммә иннииии әгүүзү бикә мин гәзәәби җәһәннәмә үә мин гәзәәбиль-кабьри үә әгүүзү бикә миң фитнәтиль-мәсиихид-дәҗҗәәл үә әгүүзү бикә миң фитнәтиль-мәхьйәә үә-ль-мәмәәт" (Аллаһым! Җәһәннәм газабыннан, кабер газабыннан, ялганчы Мәсихнең (Дәҗҗалның) фетнәсеннән, үлем һәм яшәү фетнәләреннән сиңа сыенам).** (Нәвәви, әл-Әзкар: 28).

РӘХМӘТЕҢӘ ИРЕШҮНЕ ӨМЕТ ИТӘБЕЗ

Быелгы Корбан бәйрәме игелекле гамәлләргә, матур башлангычларга бай булды.

Корбан гаете көнне - 4 октябрь иртәсендә республикабызның барлык мәчетләрендә Гает намазлары укылды, Аллаһны зурлаган бәйрәм хөтбәләре әйтелде, имамнарыбыз дин кардәшләребезне мөбарәк Корбан бәйрәме белән тәбрикләде.

Төп бәйрәм чарасы Кол Шәриф мәчетендә узды. Мәчетнең имам-хатыйбы Илфар хәзрәт Хәсәнов барча мөселманнарга Россия җитәкчелегенең, Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов, мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллинның котлауларын җиткерде. Илфар хәзрәт корбан сүзенең гарәпчәдән тәрҗемә иткәндә якынаю дигәнне аңлатуын әйтте. "Диндә бу якынаю бары бер мәгънәгә ия - Аллаһының рәхмәтенә ирешү. Без гыйбадәтләребез, гамәлләребез белән Аллаһка итагать күрсәтеп, Аңа якынаерга омтылабыз", - дип хәзрәт саваплы гамәлләр кылырга, мохтаҗларга, ятимнәргә, ярдәм кирәк бәндәләргә, авыруларга миһербанлы, игътибарлы, рәхимле булырга чакырды.



Ул көнне Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте "Яңа гасыр" телеканалы белән берлектә инвалид ятимнәрне тернәкләндерү приютын булдыру максатыннан "Сөючеләр фида кыла" телемарафоны уздырды. Узган ел үткәрелгән телемарафон нәтиҗәсендә Теләче районында ике бина сатып алынган иде. Ятим, сәламәтлекләре начар булган балаларны кабул итәрлек дәрәҗәгә җиткерү өчен биналарга ремонт ясарга, махсус медицина җиһазлары алырга, үзәкнең тирә-юнендәге җирлекне тәртипкә китерергә, шулай ук балаларны йөртү өчен микроавтобус алырга кирәк. Көн дәвамында телеканал аша динебезгә багышланган, мөселманнарның үрнәк гамәлләрен күрсәткән тапшырулар барды, телемарафонда катнашырга чакырган роликлар күрсәтелде. Хәзрәтләребезнең нәсыйхәтләре, вәгазьләре һәм фикер-тәкъдимнәре яңгырап торуы бәйрәмгә өстәмә бер ямь бирде.

Корбан бәйрәме көнне, марафон кысаларында, Бауман урамында кул эшләре ярминкәсе дә оештырылды. Бирәдә "Апрель" һәм "Здравушка" тернәкләндерү үзәкләренә йөрүче балаларның кул эшләре сатылды. Моннан тыш мөселман яшьләре флэшмобта катнашып, казанлыларны бәйрәм белән котлады.

Корбан бәйрәме көннәрендә республиканың бик күп мәхәлләләрендә корбан итеннән ризыклар әзерләп, мохтаҗларны, мәхәллә картларын, сабыйларны сыйладылар. Ә Диния нәзарәтенең "Зәкят" хәйрия фонды исә "Мохтаҗларны ашат" дигән акция уздырды. Казанның Мәрҗани мәчетендә әзерләнгән бәйрәм табынына, мәсәлән, 150 ләп мохтаҗ кеше чакырылган иде. Мәҗлестән соң аларның барчасына корбан итләре салынган пакетлар өләшенде. Бәйрәмнән соң "Зәкят" хәйрия фонды корбан итенең бер өлешен "Казан әниләре" оешмасына бирде. Әлеге оешмада йөзләгән күп балалы ана исәптә тора.

Корбан чалу эшләре дә быел узган еллардагыга караганда уңайлырак шартларда, кеше-кара күзеннән яшеребрәк башкарылды. Мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллин тәкъдиме белән башкаладагы, башка кайбер шәһәрләрдәге зур мәчетләр янәшәсендә ябык корбан чалу урыннары булдырылды. Ә Лаеш районының Сокуры авылындагы Юлчы" мәчете янында корбан чалу өчен махсус заманча комплекс ачылды. Монда терлекләрне кертеп ябарга, ашатырга утарлар бар. Мал чала торган җирдә канализация, җылы һәм салкын сулар үткәрелгән. Идәнгә плитә җәелгән, итне ташу өчен рельслар салынган. Бөтен калдыклар махсус контейнерларга тутырылып, эшкәртү өчен "Алабуга" икътисади зонасындагы махсус предприятиегә озатыла.

Татарстан мөселманнары бәйрәмне мул табыннар әзерләп, кунакларга йөрешеп, әти-әниләре, туган-тумачаларының хәлләрен белешеп уздырды. Чалган корбаннарыбыз, кылган хаҗларыбызны Аллаһ Раббыбыз кабул итеп, туган җиребездә тыныч-тату, бәхетле-бәрәкәтле гомерләр кичерергә насыйп булсын!

ХАҖЛАРЫГЫЗ КАБУЛ БУЛСЫН!

Татарстан хаҗиларын "Казан" халыкара аэропортында туганнары, якыннары һәм "ДУМ РТ ХАДЖ" программасын тормышка ашыручылар, Диния нәзарәте вәкилләре каршы алды. Хаҗиларга үзенчәлекле бүләкләр - сувенирлар һәм хаҗиларның Гарәп Әмирлегендә төшерелгән фотоларыннан, хаҗ турындагы фильм һәм клиплардан торган диск, аудиокитаплар тапшырдылар.

Хаҗиларның беренче төркеме изге сәфәргә Казаннан 25 сентябрьдә кузгалган иде. Аларны озатырга Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин да килде һәм үзенең нәсыйхәтләрен, изге теләк-догаларын җиткерде. Хәзрәт быелгы хаҗ сәфәрен оештыруда берникадәр үзгәрешләр кертелүе хакында сөйләде. Мәккәдәге мәчетне төзекләндерү сәбәпле квоталар саны киметелүен, Россиягә бирелгән 16400 квотаның 1800 е Татарстанга туры килүен хәбәр итте. Моннан тыш Согуд Гарәбстанының хаҗ оешмасы таләбе буенча, соңгы 5 ел эчендә хаҗ кылмаганнар гына хаҗга бара алачагын әйтте.

28 сентябрь төнендә Татарстан хаҗиларының соңгы төркеме Мәккәгә килеп җитте. Шулай итеп, татарстанлылар олы хаҗ кылу гыйбадәтләренә әзерләнә башладылар. Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин килеп, аларның яшәү шартлары белән танышты, хатын-кызлар, ир-атлар өчен әзерләнгән бүлмәләрне, ашханәне, уку залын карады һәм дин кардәшләребез белән аралашты, аларга үзенең җылы теләкләрен җиткерде.

Татарстан хаҗилары изге сәфәрдә татар ашлары белән тукланды. Моның өчен алар белән махсус пешекчеләр дә барды. Шулай ук хаҗиларның сәламәтлеген 15 табиб кайгыртты.

***

5 октябрьдә Согуд Гарәбстаны Әмирлегенә ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов җитәкчелегендәге Татарстан делегациясе Согуд Гарәбстаны Әмирлегенең Галиҗәнаб Әмир Абдалла ибн Абдел-Азиз Әл Согуд исеменнән Корбан гаетенә багышлап уздырылган тантаналы кабул итү мәҗлесендә катнашты. Татарстан делегациясе составында Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте рәисе, мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллин, ТР Президенты Аппараты җитәкчесе Әсгать Сәфәров, Татарстан Республикасы Президентының халыкара мәсьәләләр буенча киңәшчесе Радик Гыйматдинов та бар иде. Согуд Гарәбстанына эш сәфәре кысаларында Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнеханов башта Ислам хезмәттәшлеге оешмасы җитәкчелеге, Мәккә провинциясе Әмире шахзадә Маш'ала ибне Абдалла ибне Абдел-Азиз Әл Согуд белән очрашты, мөселманнарның изге урыннарына хаҗ кылды.

***

Быел, мәгълүм булганча, мөселманнар "Хаҗ Әкбәр" хаҗын үтәделәр, Гарәфә көне җомгага туры килгәндә кылынган хаҗ гыйбадәте әнә шулай дип атала."ДУМ РТ ХАДЖ" вәкилләре әйтүенчә, быелгы хаҗ сәфәре оешкан төстә, уңышлы үткән. Безнең мөселманнар барлык хаҗ йолаларын әбү хәнифә мәзһәбе таләпләренә туры китереп башкарып чыкканнар. 2 ноябрь көнне алар кунакханәдән Минадагы чатыр шәһәрчегенә килгәннәр, җомга көнне иртә белән Гарәфәт тавына күчкәннәр. Бу урында хаҗилар ихластан, күз яшьләре белән Аллаһ Раббыбыздан гөнаһларын ярлыкауны сорап дога кылганнар. Аннары Мөздәлифә аша Минага кайтып, шайтанга таш ату һәм корбан чалу йолаларын башкарганнар, Мәдинәдә Пәйгамбәребез (с.г.в.) мәчетендә гыйбадәт кылганнар.

Хаҗи-хаҗияләребезнең хаҗларын Аллаһ Раббыбыз кабуллардан кылса иде!

БАЛАЛАРНЫ БОРЫНГЫЛАРЧА ҮСТЕРӘ БЕЛМИБЕЗ

Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим!

Коръәннең күпләгән аятьләрендә иман һәм игелекле эшләр мөселманлыкны билгеләүче сыйфатлар итеп күрсәтелә. Моны һәммәбез дә укып беләбез. Ә тормышыбызда, яшәешебездә ничегрәк икән? Кылган гамәлләребез, эшләребез шәригатькә туры киләме? Үзебездән соң иманлы, игелекле балалар калдыруны кайгыртабызмы? Шул турыда сөйләшәсем, киңәшәсем килгән иде.

1983 нче елдан бирле булдыра алган кадәр халкыбызга ислам дине таләпләрен, Пәйгамбәребез (с.г.в.) хәдисләрен, шәригать хөкемнәрен, әдәп-әхлак, рухи байлык, илгә-көнгә ничек хезмәт итәргә кирәклеге, җибәргән ялгышларыбыз турында ачыктан-ачык сөйләп киләм. Чөнки бөтен кеше дә мулла-абыстай гаиләсендә туып үсмәгән бит. Ә без бу кагыйдәләрне күреп, өйрәнеп үстек. Әти-әни гомер буе үзләренең гыйлемнәрен кешеләргә өйрәтеп, шулар белән гамәл кылып яшәделәр.

Кичләрен әниебез безгә бик яратып пәйгамбәрләр тарихын сөйли торган иде. Бервакытны ул Ибраһим (г.с.) заманында булган бер вакыйганы сөйләде: "Өйнең хуҗасы атка атланып ауга китә. Ул киткәч, өйгә кунак килә, хәл-әхвәл сораша. Хуҗабикә картка хөрмәт күрсәтмичә, хәтта су да бирмичә, киткәнен тәрәзәсеннән генә карап кала. Шулай да тәрәзә аша: "Ирем кайткач, нәрсә дип әйтим?" - дип сорый.

- Иреңә әйт, өегезнең миче бик түрдә икән, сүтеп, яңасын чыгарсын! - ди карт.

Әлеге хикәя бик хикмәтле һәм озын. Биредә сүз, әлбәттә, мич турында түгел, яшь хатынның әдәпсезлеге турында бара. Ир юлаучы әйткән сүзләрнең мәгънәсенә төшенә һәм хатынын аерып, башкага өйләнә. Күпмедер вакытлар үткәч, карт янә боларның өенә килә. Сәлам бирә, хәл-әхвәл сораша. Яшь хатын картны йомшак сүзләре белән каршы ала. Бик арыгансыздыр, дип аттан төшәргә ярдәм итә, иренең хәзер кайтып җитәчәген әйтә. Ял итәргә, көтеп торырга кыстый, чәен өлгертеп табын әзерли. Юлаучының күңеле була, рәхмәтләр әйтеп хәер-догасын кыла. "Ирең кайткач әйт, кызым, өегез бик уңайлы икән", - дип китеп тә бара. Ире, картның әйткәннәрен аңлап, хатыныннан бик канәгать кала.

"Алар заманында аерылышулар бер дә булмаган, хәзер исә бу "чир" елдан-ел арта бара. Минемчә, сәбәбе дә ачык. Без балаларыбызны борынгыларча үстерә белмибез. Алар уен, сөйләм, вәгазь, аңлату, күрсәтү, дини йолалар ярдәмендә баласын һәрдаим киләчәк тормышка хәзерләп килгән"

Нинди авыр еллар булуга карамастан, әниебез төрле уеннар уйнатып, хикәятләр сөйләп, безнең киләчәк тормышыбызга юл салган. Ә хәзер, бала килеп сыена башласа, аны уенчыклары янына борып җибәрәбез, телевизорда яхшы, кызыклы тапшыру бара, имеш. Я булмаса, компьютерда нәрсәдер эзлибез. Менә бу инде безнең төп ялгышыбыз! Аерыл бер минутка булса да, ярат, сөйләш, аңларга тырыш балаңның күңелен. Тәрбияви сүзләр әйткәлә колагына, уенын тиешле юлга юнәлт!

Борынгылар үз балалары белән ана карынында чакта ук сөйләшә башлаган. Бала үстергәндә аңа үзе үрнәк булган, үз-үзеңне тоту кагыйдәләрен, әдәп-әхлакны, ир һәм хатын вазифаларын, дини яктан килеп, баласының аңына сеңдергән. Кычкырып көлү, кеше каршында киерелеп кием кию, кешеләр сөйләшкәндә сүзне бүлдерү, олылар сөйләменә катышу, каршыга очраган кешегә юл бирмәү, бәрелеп китү, үзеңнән олыракларга торып урын бирмәү, ир яки хатынның бер-берсенә каршы дәшүе, урлашу, гайбәт сөйләү кебек ярамаган эшләр башкару - без бала вакытларда бик оят гамәлләрдән санала иде.

Инде кияүгә чыгасы кызга һәр сәгать саен диярлек вәгазь сөйлиләр. Кайнана-кайнаталарына игътибарлы булырга, хөрмәт итәргә, ягымлы, мәрхәмәтле булырга, ире ачулы чакта телне тыярга өйрәтәләр иде. Элекке заманда өчәр-дүртәр бүлмә беребездә дә юк, шул бер бүлмә. "Кызым сиңа әйтәм, киленем син тыңла!"- дигән әйтемдәге кебек, олылар нәрсә сөйләшсә, шуны без дә тыңлыйбыз. Киләчәктә болар кирәк булачак, тиешлесен ишетеп калсыннар, дип безнең алда сөйләшкәннәрдер инде. "Туганый! Әгәр бер-береңә юл куймасаң, киңәшмәсәң, барына канәгать була белмәсәң, ялкау булсаң, тормышта ир белән торып булмый шул. Әлхәмдүлилләһ, без - киленнәр барыбыз да тырыш булдык. Кеше көлдермәдек. Әти-әниләребезне кечерәйтмәдек", - дип көлешеп тә куялар иде.

Алар заманында аерылышулар бер дә булмаган, хәзер исә бу "чир" елдан-ел арта бара. Минемчә, сәбәбе дә ачык. Без балаларыбызны борынгыларча үстерә белмибез. Алар уен, сөйләм, вәгазь, аңлату, күрсәтү, дини йолалар ярдәмендә баласын һәрдаим киләчәк тормышка хәзерләп килгән. Ә без ни эшлибез? Ашатабыз, эчертәбез, укытабыз, диплом алдырабыз, машинасын да алып бирәбез, фатир ачкычын да кулларына тоттырабыз. Тормышлар бик авыр, ярдәм итәбез, янәсе. Ата-анага хезмәт итмәгән, компьютер, телефон белән генә уйнап үскән баладан ни көтәсең?

Еш кына бүгенге яшьләребезгә, әти-әниләргә, шул исәптән олы яшьтәгеләргә дә, милләтенә карамастан, сорау бирәм:

- Сез кызыгызны, улыгызны тормышка хәзерлисезме? Ир-хатын вазифаларын, бала тәрбияләү тәртипләрен өйрәтәсезме? Никахның озын гомерле булуы өчен ничек яшәргә кирәген аңлатасызмы?

- Аңа вакыт бармыни? Без эшлибез ич! - диләр алар.

Җәмәгать, гаепләмәгез мине! Ачыктан-ачык әйтәм, тамагы тук, өсте бөтен баланы кызганган булып, эшсез үстереп, без аны үзебез бәхетсез итәбез. Эш сөймәгән бала беркая да сыймый ул. Соңыннан ата-ана үзе дә ялгышын таный башлый, әмма соң була инде.

"Хәзер исә кайсы гына районга, авылга барма, бәрәңге бакчасында чүп үләне үсә. Картайдык, имеш. Ә шәһәрдән кайткан кунаклар, ул-киленнәр, кияү-кызлар, балалар, оныклар бәрәңге чүбен дә утый алмаслыкмыни? Алар телевизор карап, телефон уйнатып утыра, ә җир, мескенкәем, исраф булып ята"

Кайберләребез хәтта дингә дә өстәмә эш дип карый. Аллаһы тәгаләгә ышанып, иман китергән кешеләр борынгылар кебек ихлас күңелдән үтиләрме икән шәригать таләпләрен, дигән сорау туа. Бер мөслимә, иренә ачуы килсә, ашаган вакытында аш тәлинкәсенә төкерә икән, мин әнә шундый хәлләрне ишетеп беләм. Дингә ышанмаган кеше дә мондый түбәнлеккә төшмәс! Димәк, ул динне яхшы, тәртипле иргә чыгу өчен генә файдаланган.

Никахны саклау ирнең дә, хатынның да хезмәткә мөнәсәбәтенә турыдан-туры бәйле, минемчә. Бөтен гаиләң белән иртәдән кичкә чаклы хезмәт итсәң, кирәкмәгән юк-бар уйларга, шөгыльләргә вакыт калмый ул, тормышың да җитеш була. Борынгылар әнә сука белән җирен сукалаган, бакчасын көрәк белән казып, бәрәңгесен утырткан. Ашарына икмәге булмаган, ач-ялангач булган, әмма баласын тормыш итәргә, хезмәткә, үз һөнәренә өйрәткән, әдәп-әхлак, рухи байлык, барына канәгать булуны, туган илгә, туган туфрагына ихлас күңеленнән хезмәт итүне баласына бурыч итеп йөкләгән.

Бер елны әтиебез 6 ай урын өстендә, әниебез бер ел буена дөм сукыр булып яшәде. Мин дүртенчедә, уртанчы апабыз җиденче сыйныфта. Көндез генә бакчаны казып бетерә алмабыз, кешеләр бәрәңгене утырта башларлар дип, башкалардан калышмаска тырышып, төннәрен бакчага чыгып, ай яктысында җир казый идек. Сугышы да бетәр әле, әти-әни дә терелер, иншә Аллаһ, дип алга таба өмет белән яшәдек. Әтиебез 90 яше белән барганда да бакчасына бәрәңгесен утырттырды, капка баганаларын алыштыртты. Менә ул борынгыларның тормышка булган карашы, хезмәткә мөнәсәбәте, сабырлыгы һәм зирәклеге.

Хәзер исә кайсы гына районга, авылга барма, бәрәңге бакчасында чүп үләне үсә. Картайдык, имеш. Ә шәһәрдән кайткан кунаклар, ул-киленнәр, кияү-кызлар, балалар, оныклар бәрәңге чүбен дә утый алмаслыкмыни? Алар телевизор карап, телефон уйнатып утыра, ә җир, мескенкәем, исраф булып ята. Аллаһы тәгаләгә ничек җавап бирербез? Адәм баласының дөньядагы бәхете - аның хезмәтендә, тәрбиясендә, рухи байлыгында. Балаларыбызны акчалы, бай итәргә бик тырышабыз, ә аларның әхлакый-рухи байлыгы турында уйлап караганыбыз бармы? Ай-һай, күп эшләр эшлисебез бар әле безнең! Борынгы әби-бабаларыбыз кебек ир баланы чын гаилә башлыгы булырга, кыз баланы ана, хатын булып яшәргә, тормыш йөген иңгә-иң куеп бергә тартырга өйрәтәсебез бар әле.

Дин, әдәп-әхлак кагыйдәләре һәрберебезнең тормышында якты маяк булса иде! Гомеркәйләрнең кадерен, ямен белеп, саулык-сәламәтлек, тынычлык белән, бәхетле-бәрәкәтле гомерләр кичерергә язсын! Теләкләрем "тузмый торган бүләк" булып ирешеп, Раббыбыз һәрбарчагызга ике дөнья рәхәтенә ирешергә насыйп итсен!

Ихтирам белән,

Сәйдә абыстай
АППАКОВА

25 нче октябрь - мөселманнарның Ай календаре буенча яңа 1436 нчы һиҗри ел башы

МӨХӘРРӘМ АЕ ҺӘМ ҺИҖРИ ЯҢА ЕЛ

Бөтен галәмнәрнең Раббысы булган Аллаһы сүбхәәнәһү үә тәгаләгә иксез-чиксез хәмде-сәна (мактауларыбыз), шөкраналарыбыз, мактауларыбыз булса иде. Аның сөекле илчесе газиз пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу гәләйһи үә сәлләмгә, аның гаиләсенә, барлык сахәбәләренә сәламнәребез һәм салаватларыбыз булса иде.

Аллаһы тәгалә Коръән Кәримдә болай дип әйтә: **"Шөбһә юктыр, Аллаһы тәгаләнең шигарьләрен (хөкемнәрен) хөрмәт иткән кешенең күңеле тәкъвалыктадыр"**.

Чыннан да, һиҗри ел башы - Раббыбызның иң олы шигарьләренең берсе. Әгәр без тәкъвалылардан булырга теләсәк, аны олыларга тиеш. Әмма аның серләрен, хикмәтләрен, хасиятләрен белмичә тиешлечә олылап булмый.

Һиҗри хисап, нәрсә соң ул? Аның тарихы һәм серләре нинди? Бүгенге вәгазебездә менә шул сорауларга җавап бирербез, иншаллаһ.

"Һиҗра" сүзе, гарәп теленнән тәрҗемә иткәндә, бер урыннан икенче урынга күчеп китү дигән мәгънәне аңлата. Билгеле булганча, Мәккә шәһәрендә дин тоту һәм дәгъвәт эшен алып бару бик кыенлашканнан соң, Аллаһы тәгаләнең боерыгы буенча, сөекле пәйгамбәребез саллэллаһу гәләйһи үә сәлләм һәм сахәбәләр Мәдинә шәһәренә күчеп китә. Менә шул көннәрдән башлап, нурлы Мәдинәдә иң беренче хакыйкый мөселман җәмгыяте төзелә. Мәдинәдән ислам, иман һәм Коръән нуры, әдәп-әхлак, тән һәм җан пакьлеге бөтен дөньяга тарала. Димәк, һиҗра, безгә - мөселманнарга гына түгел, бәлки бөтен дөнья тарихына вә тормышына олы үзгәреш кертә. Һиҗра - Раббыбызның олы нигъмәте. Һиҗри - ел хисабы милади кебек үк - 12 айдан тора, әмма, ай фазалары буенча хисап алып барылуы сәбәпле, ел саен 11 көнгә кыскарак килә.

Кайдан килде соң ул һиҗри ел хисабы? Ни өчен аны һиҗрадан башладылар? Моның тарихы пәйгамбәребез саллэллаһу гәләйһи үә сәлләмгә әйләнеп кайта. Кайбер риваятьләрдә әйтелгәнчә, пәйгамбәребез саллэллаһу гәләйһи үә сәлләм исән чагында ук аны үзе кулланган, әмма аның вафатыннан соң сахәбәләр һиҗри ел хисабы турында онытып җибәргән. Гомәр (Аллаһы аңардан разый булса иде) заманы килеп җитә. Менә шул вакытта Гомәргә (Аллаһы аңардан разый булса иде) дәүләтнең төрле төбәкләреннән хатлар килә, ул хатларда көне һәм ае язылган, елы билгеләнмәгән була. Шул сәбәпле, Гомәр (Аллаһы аңардан разый булса иде) олы сахәбәләрдән торган шура җыеп, бу мәсьәләне күтәрә. Берәүләр, беренче ел итеп, пәйгамбәребез саллэллаһу гәләйһи үә сәлләм туган елны сайларга дип тәкъдим итә. Әмма ул вакытта ислам диненнән искә дә алучы кеше булмый, шул сәбәпле бу фикерне кире кагалар. Башкалар исә, беренче ел итеп, пәйгамбәрлек башланган елны сайларга тәкъдим итә. Бу фикер дә кире кагыла, чөнки ул елны сөекле пәйгамбәребездән (саллэллаһу гәләйһи үә сәлләм) башка җир йөзендә мөселманнар булмый. Өченчеләре исә, беренче ел итеп, пәйгамбәребез саллэллаһу гәләйһи үә сәлләмнең вафат булган елын сайларга тәкъдим итә. Ләкин башкаларның ислам тәкъвимен (календарен) кайгылы елдан башлыйсылары килми. Шунда Гали ибне Әбү Талиб (Аллаһы аңардан разый булса иде) тәкъдиме кабул ителә - елларны Мөхәммәд пәйгамбәрнең (саллэллаһу гәләйһи үә сәлләм) Мәккәдән Мәдинәгә күчкән елыннан саный башларга булганнар. Гали (Аллаһы аңардан разый булса иде) болай дип аңлаткан: *"Бу елны, Аллаһының рәхмәте белән, пәйгамбәребез саллэллаһу гәләйһи үә сәлләм һәм ислам дине сакланды, яңа адым ясалды. Ислам дине яңадан туган шикелле булды"*. Бу - безнең бөек тарихыбыз, без аны беркайчан да онытырга тиеш түгел.

Изге мөхәррәм ае - бик мөкатдәс (хөрмәтле - Ред.) ай. Бу айда бер бик олы көн бар - ул Гашүрә көне. Ул *мөхәррәм аеның 10 нчы көнендә* туры килә (милади календарь буенча быел 3 нче ноябрьдә булачак). Гарәп теленнән *"гашүрә"* сүзе "унынчы" дип тәрҗемә ителә. Пәйгамбәребез саллэллаһу гәләйһи үә сәлләм Мәккәи-Мөкәррәмә шәһәреннән Мәдинәи-Мөнәвәрә шәһәренә һиҗрәт кылганнан соң, шушында яшәгән яһүдиләрнең бу көндә ураза тотканын белгән һәм алардан моның сәбәбен сораган. Шунда яһүдиләр, җавап итеп, болай дигән: *"Бу көнне Аллаһы тәгалә пәйгамбәребез Муса галәйһиссәламне Фиргавеннән һәм аның гаскәреннән коткарган. Шуңа күрә без, бу көнне олылап, ураза тотабыз"*. Пәйгамбәребез саллэллаһу гәләйһи үә сәлләм аларга болай дип җавап биргән: *"Муса пәйгамбәр сезгә караганда безгә якынрак"*. Рәсүлебез Мөхәммәд саллэллаһу гәләйһи үә сәлләм шушы көнне уразада булган. Ул үзенең өммәтен, мөэмин-мөселманнарны да бу көндә ураза тотарга өндәгән. Гашүрә көнендә башка күп кенә бөек вакыйгалар да булган. Бу көнне Бөек Раббыбыз дөньяны, Адәм галәйһиссәламне яраткан, Нух галәйһиссәламнең көймәсе тауга килеп җиткән, Ибраһим галәйһиссәлам туган һәм мәҗүсиләрнең учагыннан коткарылган, Әйюб галәйһиссәлам авыруыннан терелгән, Йосыф галәйһиссәлам олы дәрәҗәләргә ия булган һәм башка бик күп олы вакыйгалар булып үткән.

Ураза - бөек гыйбадәтләрдәндер. Аллаһы тәгалә кодсихәдистә әйткән: *"Ураза - Минем өчен хас гыйбадәттер. Аның әҗерен Үзем бирермен" (Бохари, Муслим)*. Намаз, зәкят һәм хаҗ гыйбадәтләре дә Аллаһы өчендер, ләкин уразаның үзенчәлеге - Аллаһы белән мөэминнең арасында сер булуында, шуның өчен аның әҗере дә олы. Ни өчен уразаны Аллаһы тәгалә белән мөэмин арасындагы яшерен гыйбадәт дибез? Намаз укысак, зәкят бирсәк, хаҗга барсак - моннан адәмнәр хәбәрдар була, әмма ураза тотканыбызны фәкать үзебез һәм Аллаһы тәгалә генә белә. Шулай булгач, кардәшләрем, ураза гыйбадәте аша без Раббыбызның чиксез рәхмәтенә ирешә алабыз.

Мөхәррәм ае да - рәҗәп, рамазан һәм башка айлар кебек үк - изге-шәрәф ай булып санала. Әгәр ай буе ураза тоту хәлебездән килмәсә, без унынчы һәм унберенче көннәрендә генә булса да ураза тотарга тырышырга тиеш. Ә иң хәерлесе - рәттән өч көн ураза тоту: мөхәррәм аеның 9 нчы, 10 нчы һәм 11 нче көннәрен ураза белән уздырсак Аллаһының чиксез рәхмәтләренә ирешербез.

Ләкин без уразаларны нәрсә өчен тотабыз соң? Әлбәттә, гөнаһлардан арыну, пакьләнү өчен. Кайберәүләр: "Нигә һаман шул гөнаһлар турында гына сүз алып барасыз", - дип әйтергә мөмкин. Моңа җавап итеп, пәйгамбәребез саллэллаһу гәләйһи үә сәлләмнең бер хәдисен китерәсем килә: *"Адәм балаларының кылган гөнаһлары, эшләгән хата-кимчелекләре аркасында аларның җилкәсенә бәла-казалар, хәсрәтләр килә. Ләкин кеше үзенең хатасын танып, Аллаһы Раббыбыздан гафу үтенеп, шул гөнаһларыннан тәүбә кылса, шуның белән аның бәла-казалары да китәр"*. Адәм баласы үзенең башына кайгы-хәсрәт килгәч, гаепне үзеннән күрергә теләмичә, башкалардан эзли башлый. Ләкин, күпчелек вакытта, адәм баласының үзе кылган гөнаһлары аркасында аның үз башына бәла-казалар килә. Шуңа күрә пәйгамбәребез саллэллаһу гәләйһи үә сәлләмнән: *"Мөхәррәм аеның Гашүрә көнендә ураза тотсаң, нинди савапларга ирешергә була соң?"* - дип соралгач, ул: *"Узган елыгызның гөнаһларын, хата-кимчелекләрен Аллаһы тәгалә гафу итәр, истигъфар кылыр"*, - дигән.

Мөхәррәм ае - изге ай. Бу айда кылынган гамәл-гыйбадәтләребезнең, игелекле эшләребезнең әҗер-савабын Аллаһы тәгалә бик күп мәртәбәләргә арттыра һәм аның хакыйкый әҗерен без Аллаһы Раббыбыз хозурындагы Кыямәт көнендә генә аңлаячакбыз. Ләкин, шул ук вакытта, адәм баласы гөнаһ кылса, аның гөнаһлары өчен дә җәза булачак. Шуны истә тотсак иде. Хакыйкый инану белән инанып, мөхәррәм айларының һәр көнен гамәл-гыйбадәт кылып уздырырга тырышсак иде. Нәфел уразалары, нәфел намазлары, игелекле эшләр булсыны, иң мөһиме - шуларны кылырга ашыгып-ашкынып торсак иде. Бер-беребезгә мәрхәмәтле булып иминлек таратсак иде. Кайберәүләр: "Гыйбадәт ул - фәкать шушы уразадан, намаздан гына гыйбарәт", - дип уйлый. Болай дип уйлаучылар зур хата кыла. Гыйбадәтебез - бер-беребезгә игелек кылу, мәрхәмәтле булу, шәфкатьлелек күрсәтү, ярдәм кулы сузарга тырышу, ярдәмнең нинди дә - матди исә рухыймы - безнең өчен гыйбадәт икәнлеген онытмыйча, Аллаһыга ялварып, игелекле эшләр кылырга ашыксак иде. Пәйгамбәребез саллэллаһу гәләйһи үә сәлләм дә бит: *"Кил-әсе елның мөхәррәм аен күрә алсам, һичшиксез, ураза тотар идем"*, - дип әйткән булган.

Аллаһы Раббыбыз безгә быелгы мөхәррәм аен күрергә насыйп иткән икән, ураза тотып, гамәл-гыйбадәттә булып, Раббыбызның чиксез рәхмәтенә - шушы дөньяның да, ахирәт тормышының да бәхет-сәгадәтенә ирешергә Аллаһы Раббыбыз һәрбарчаларыбызга да насыйп итсә иде.

Вәгазьне Үзәкләшкән дини оешма - Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәтенең дәгъвәт булеге әзерләде

ГАШҮРӘ - АЛЛАҺНЫҢ ЧИКСЕЗ РӘХМӘТЕ КӨНЕ

Мөхәррәм аеның унынчы көнендә бөтен мөселман дөньясы Гашүрә көнен бәйрәм итә. Пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа саллэллаһу галәйһи үә сәлләм: "Аллаһы тәгалә җирне вә күкләрне Гашүрә көнендә бар итте, Ләүхелмәхфүз илә каләмне дә Гашүрә көнендә булдырды. Атабыз Адәм галәйһиссәлләмне белән Анабыз Һәва радияллаһу ганһәне Гашүрә көнендә яралтты. Җәннәтне бу көнне булдырды һәм Атабыз Адәм галәйһиссәлләмне оҗмахка Гашүрә көнне кертте", - диде.

Бу көнне бик күп пәйгамбәрләр Аллаһ Раббыбызның рәхмәтенә ирешкән: Нух галәйһиссәлләмнең көймәсе тауга килеп җиткән, Ибраһим галәйһиссәлләм туган һәм мәҗүсиләрнең учагыннан коткарылган, Әюб галәйһиссәлләм авыруыннан терелгән, Йосыф галәйһиссәлләм олуг дәрәҗәләргә ирешкән һ.б.

Гашүрә көнне түбәндәге гамәлләрне үтәү киңәш ителә:

1. 2 яки 3 көн ураза тотарга. Мөхәррәмнең 9-10,10-11, 9-10-11нче көннәрендә ураза тоту да бик саваплы. Бер генә көн ураза тоту киңәш ителми.
2. Авыз ачтырырга, ифтар үткәрергә. Әлхәмдүлилләһ, авылларда да мәчетләрдә бу эш гадәткә кереп бара.
3. Госел коенырга.
4. Мөмкин кадәр күбрәк: "Әстәгъфируллааһиәл гә- зыйм", - дип әйтергә.
5. Авыру кешеләрнең хәлен белергә.
6. Кояш чыгып сөңге буе күтәрелгәч, ишрак намазы вакытында 2-12 рәкәгатьле намаз укырга.
7. 10 мөселман кешегә сәлам бирергә.
8. "Хәсбиәллааһү үә нигмәл үәкииил. Нигмәл мәүлә үә нигмәл нәсыыйр. Гуфраанәкә раббәнәә үә иләйкәл мәсыыйр", - дип 70 мәртәбә укырга.
9. Сәдака бирергә. "Гашүрә көнне берәү тары бөртеге кадәр генә сәдака бирсә, Аллаһ аңа Өхед тавы кадәр савап бирер", - диде Пәйгамбәребез (с.г.в.).
10. Ятимнәрне сөендерергә.
11. Гаиләдә мул итеп бәйрәм табыны әзерләргә. Гашүрә көнне мул табын әзерләгән йортның ел буе ризыгы киң булыр, иншә Аллаһ.
12. Күплап тәсбих-зикер әйтергә, дога кылырга, Коръән укырга.

АЛТЫДА БЕЛГӘН АЛТМЫШТА ОНЫТЫЛМАС

"Хузур" нәшрият йорты һәм "ХузурТВ" проектларының берсе булган "Азбука ислама" - "Ислам әлифбасы" тапшыруы күптән түгел генә эфирда күрсәтелә башлавына карамастан, тамашачылар аны яратып та өлгерде. Кайсы ягы белән үзенә җәлеп итте икән ул әти-әниләрне? Шул сорауга җавап эзләп, без тапшыруның авторы һәм алып баручысы *Ландыш ИБРАҺИМОВА*га мөрәҗәгать иттек.

- Игътибар иткәнегез бар микән, телевидение тапшырулары, бигрәк тә дини тапшырулар, башлыча, өлкәннәргә адреслана. Олылар өчен китаплар бастырыла, вәгазьләр сөйләнә, тапшырулар әзерләнә. Хәтта бәйрәм вакытларында да балалар берникадәр читтә кала сыман. Әмма Пәйгамбәребез Мөхәммәднең (с.г.в.) тормыш юлын өйрәнгәндә күрәбез: ул сабыйларны һәрвакыт игътибар үзәгендә тоткан, нинди генә мөһим, ашыгыч эшләр белән шөгыльләнүенә карамастан, алар белән аралашырга өлгергән, аларны мактаган, башларыннан сыйпаган, хәл-әхвәлләре белән кызыксынып, кирәк урында кисәтү дә ясаган.

Аллаһка шөкер, соңгы берничә елда бездә дә яшь буынга дини тәрбия бирү өлкәсендә төрле чаралар күрелә башлады: балаларга дин турында сөйләүче китаплар бастырыла, аларны ислам кыйммәтләренә өйрәтә торган төрле курслар ачыла, дини бәйрәм чаралары оештырыла. "Ислам әлифбасы" тапшыруы да алда саналып киткән чараларның берсе буларак әти-әниләрне үзенә җәлеп иткәндер, мөгаен.

Икенче яктан карасак, хәзер балалар өчен аерым каналлар эшләп килә. Әмма динебез турында балаларга юнәлдерелгән тапшырулар сирәк. Шул сәбәпле нарасыен ислам мохитендә тәрбияләүне максат иткән әти-әни баласы карый торган һәр тапшыруны иләк аша үткәрергә мәҗбүр. Сабыйлар һәр нәрсәне үзләренә сеңдереп, акны акка, караны карага аера алмыйлар, аларның нинди мәгълүмат кабул итүләрен тикшерүдә тоту мөһим. Ә мөселманнар тарафыннан төшерелгән, ислам турындагы тапшыруларны бернинди шөбһәсез карарга була. Әти-әниләр мондый тапшыруларга мохтаҗ. Бу тапшырудан балам гына түгел, үзем дә күп нәрсәгә өйрәндем, дип әйтүчеләр булды.

- Бу тапшыруның максат - бурычлары нидән гыйбарәт?

- "Ислам әлифбасы" тапшыруының максаты - мәктәпкәчә яшьтәге балаларга гарәп әлифбасын өйрәтү белән бер рәттән, ислам кануннары белән таныштыру. Балалар өчен әзерләнгән тапшыруның уен формасында булуы да шарт.

Бүгенге көндә, Аллаһка шөкер, күп әти-әниләр сабыйларына кечкенәдән үк исламның 5 баганасын, динебез турындагы төп мәгълүматны өйрәтеп үстерә. Тапшыруның алар өчен дә кызык булуы кирәк. Әгәр тапшыру "намаз укырга, ураза тотарга кирәк" дигән форматта гына алып барылса, бу балаларга ялыктыргыч булыр иде. Без динебезгә башка яктан сукмак салырга теләдек: сабый тирә-юньгә карап, фикерләргә, табигатьнең һәр күренешеннән Аллаһ тәгаләнең хикмәтен, кодрәтен күрә белергә өйрәнергә тиеш. Берсүзсез тапшыруларыбызда намаз, ураза, зәкят, хаҗ турында да сөйләшәбез, әмма бала кайсы тапшыруда ни көткәнен белмәү сәбәпле, аны кызыксынып көтеп алачак.

Балалар иҗади яктан да үсәргә тиешләр. Кызганыч, безнең укыту системасында моңа аз урын бирелә. Шуңа тапшыру ахырында балалар төрле материаллар, төрле ысуллар кулланып, темага бәйләнешле берәр кул эше ясыйлар.

- Тапшыру вакыт ягыннан кыска булуга карамастан, балалар Коръән сүрәләрен дә ятларга өлгерәләр. Кечкенәдән үк Коръән сүрәләрен ятлату кирәк микән?

- Адәм баласы кечкенәдән үк Коръән аятьләрен ятлап, Коръән кануннарын үз тормышында куллана белеп үсәргә тиеш. Икенчедән, балалар тиз отып алучан, зирәк була. Кечкенәдән Корьән аятьләре, шигырьләр ятлау кешенең хәтерен үстерүдә ярдәм итә. Бала чакта алган мәгълүмат кешенең хәтерендә гомер буе саклана. Татар халкы әйткәнчә, алтыда белгән алтмышта онытылмас. Шул сәбәпләрне истә тотып, без тапшыруда Коръән сүрәләрен ятлыйбыз һәм аларда нәрсә турында сүз барганына да тукталабыз.

- Тапшыруның аудиториясе кемнәр? Нинди телдә чыга һәм аны кайда карап була?

- Бу тапшыру, гомумән алганда, мәктәпкәчә яшьтәге балалар өчен дип әзерләнә. Әмма һәркем, шул исәптән әти-әниләр дә, әби-бабайлар да файдалы һәм кызыклы мәгълүмат таба алырлар, дип өметләнәбез. Әлегә тапшыру "Азбука ислама" исемендә рус телендә эфирга чыга, әмма алга таба, Аллаһ насыйп итсә, татар телендә дә төшерү нияттә бар. Тапшыруны Хузур ТВ ның рәсми сайтында huzurtv.ru адресы буенча һәм социаль челтәрләрдә карарга була.

- Ландыш, яшь кенә булуыңа карамастан, син балалар белән уртак телне бик тиз тапкансың, алар белән шундый җиңел аралашасың. Чыннан да, безгә экраннан күренгәнчә җиңелме алар белән аралашу?

- Балалар дөньясы зурлар дөньясыннан нык аерыла. Балалар белән аралашканда мәсьәләгә алар күзлегеннән карый белергә өйрәнергә кирәк. Олыларга бу шактый авыр. Олыларга вак тоелган мәсьәлә бала өчен тулы бер фаҗига булырга мөмкин. Без һәрвакыт каядыр ашыгабыз, баланың көйсезлекләре безгә юк-бар нәрсә булып тоела. Әти-әни - бала арасындагы аңлашылмаучанлык та күп очракта шушы нигездә чыга. Әгәр бала нәрсәнедер исенә ала икән, димәк, бу аның өчен мөһим. Олыларга мона игътибар итәргә кирәк. Балалар белән аралашуның үз кануннары, үз теле, үз фразалары, үз ысуллары бар.

- Тапшырулар әзерләгәндә син кемнең дә булса ярдәмен, теләктәшлеген тоясыңмы?

- Тапшыру әзерләү турындагы карар кабул ителгәннең беренче минутыннан диярлек юлыбызга кирәкле кешеләр чыгып торды, четерекле мәсьәләләр үзеннән-үзе чишелде. Бу Аллаһы тәгаләнең генә ярдәме һәм хикмәте. Һәм берсүзсез безнең иң якын кешеләребез, алар һәр башлангычыбызны хуплап, үз киңәшләрен, бәяләрен биреп торалар. Шулай ук тапшыруда катнашучы балаларның да, аларның әти-әниләренең дә бу проектның тормышка ашуында рольләре гаять зур.

- Телевизион тапшыруларны без экраннар аша карыйбыз, матур, бары да яхшы, шома гына бара. Хәтта үзеннән-үзе эшләнәдер кебек. Ә шулай да, тапшырулар әзерләү җиңел эш түгеллеген беләбез. Аның кухнясы белән бераз таныштырып уз әле.

- "Ислам әлифбасы" тапшыруы төрле тарафларга юл тоткан гарәп хәрефләре очраган маҗаралардан гыйбарәт. Һәр тапшыруда без бер хәрефне эзләп табып, аның белән танышабыз. Алдан сценарий языла, хәрефнең кая сәяхәт итәсе, табышмак, төрле биремнәр уйланылып, сюжет алга таба үстерелә. Балалар дәрескә зур кызыксыну белән киләләр һәм алар катнашында дәресне төшерәбез.

- Тапшыру төшерелгән студиянең дә махсус балалар өчен көйләнгән булуы сизелә...

- Тапшыру "Сабыйлар" балалар үзәгендә төшерелә. Бу үзәктә 6 айдан алып 6 яшькә кадәр балалар өчен төрледән-төрле дәресләр үткәрелә. Дәресләр татар телендә татар милли уеннарына, моңнарына, гореф-гадәтләренә нигезләнеп оештырыла. Тапшыру төшерү турындагы фикер белән үзәкнең җитәкчесе Ләйсәнне таныштыргач, ул бик теләп үзенең студиясен безгә тәкъдим итте. Башланган эшләре дәвамлы булып, Аллаһы тәгаләнең рәхмәте булсын аңа.

- Ә идеясенә килгәндә?

- Балалар өчен тапшыру әзерләү уйда йөрүгә карамастан, ул хыял булып тоела иде. "Хузур" телевидениесеннән шундый тәкъдим килгәч, куркып кына булса да ризалаштык. Телевидение хезмәткәрләре тапшыруны эфирга чыксын өчен үзләренең бар көчләрен һәм мөмкинлекләрен куялар. Камиллекнең чиге юк, диләр. Бу проектны тагын да кызыклырак, сыйфатлырак, үзәк телеканалларда баручы балалар тапшыруларына яхшы мәгънәдә көндәш булырлык; динебезнең, милләтебезнең киләчәге булган яшь буынга юнәлдерелеп, исламның төрле якларын яктырткан тапшырулар төшерәсебез килә, Аллаһ теләсә. Әмма вакыт ягыннан бик озайтасы килми, чөнки балалар өчен тапшыру аларның яшь үзенчәлекләрен истә тотып эшләнелә, ул аларны ялыктырырлык булмаска тиеш.

Әңгәмәдәш –
Эльвира МУТАВАЛОВА

"ИРЕМ БАШКАНЫ СӨЯ..."

СОРАУ. ***"Без ирем белән 6 ел бергә яшибез, ике балабыз бар. Ирем миңа өйләнгәнче бер кызны яратып йөргән булган, ул кыз хәзер кияүдә, ике баласы бар. Ике ел элек алар социаль челтәрдә аралаша башлаганнар. Шуннан бирле теге хатын ире белән әле аерылышып, әле кавышып яши. Минем ирем намазлы кеше, эчми, тартмый. Аны шайтан шулай котыртып тора, дип үз-үземне тынычландырам. Әмма күптән түгел генә ирем шул хатынны яратуын әйтте, үзем белән берни дә эшли алмыйм, ди. Мин: "Бер-берегезне шулай нык яраткач, гөнаһка керешмәгез, никах укытыгыз", - дидем. Әмма теге хатын ире белән дә аерылышырга җыенмый, минем иремне дә ычкындырмый. Нишләргә инде?"***

ҖАВАП. Бу четерекле хәлнең уңай ягы да бар. Ирегез бу хакта яшермичә үзе сөйләгән, димәк, ул сезгә ышана. Инде начар ягына килик. Ирегез ике ел дәвамында социаль челтәрдә башка хатын-кыз белән аралаша икән, димәк, никахыгызда аны нидер канәгатьләндерми. Ир белән хатын арасындагы мөнәсәбәт күпчелек очракта хатын-кыздан тора. Аның сезгә булган ихтыяҗы үзара ничек аралашуыгызга, ничек вакыт үткәрүегезгә бәйле. Шулай булгач, бөтен зирәклегегезне туплап, ирегез белән мөнәсәбәтләрне җайлау турында уйларга кирәк. Арада башка хатын-кызның барлыкка килүен хәвефле сигнал дип кенә кабул итегез. Сәбәп ул хатында түгел, аның урынында башкасы да булырга мөмкин иде. Сезнең бурыч - ирегезгә нәрсә җитмәвен ачыклау һәм шул дефицитны бетерү. Башта ике арагыздагы мөнәсәбәтләрне анализлап карагыз. Ирегез белән иртәләрегезне ничек уздырасыз? Аны эшкә ничек озатып каласыз, ничек каршы аласыз? Кичләрегез ничек уза? Хәтта кечкенә генә кайгыртучанлыгы өчен дә ирегезгә рәхмәт әйтәсезме? Аңа елмаеп карыйсызмы? Соңгы тапкыр кайчан ирегезгә соклануыгызны белдердегез? Сез аны тыңлый һәм ишетә беләсезме? Аның ярдәменә мохтаҗ булуыгызны сиздерәсезме? Ә ул сезнең ярдәмгә мохтаҗ булганда ярдәм итәсезме? Тормышыгызда ирегезне беренче урынга куясызмы? Аны сокландырырга-кызыктырырга тырышасызмы? Кием-салымыгызны еш үзгәртәсезме? Сезнең арада романтик хисләр әле дә сакланамы? Бер-берегезгә бүләкләр ясыйсызмы? Аңа нинди назлы сүзләр әйтәсез? Бәлки сезнең мөнәсәбәтләр ана белән бала мөнәсәбәтләрен хәтерләтә торгандыр? Кайбер хатыннар ирләрен аналары кебек кайгыртып, аларга ирлек сыйфатларын күрсәтергә ирек бирмиләр. Ир-атлар бит, гадәттә, үзләре хатыннарын якларга, сакларга тели. Шушы сорауларга җавап эзләгәндә нәрсәне дөрес эшләмәвегезне ачыкларга тырышыгыз, гаиләгезне ничек саклап калып була - шул хакта уйланыгыз.

Ир һәм хатын арасындагы мөнәсәбәтләр үзеңне корбан итүгә яки, киресенчә, басым ясауга корылырга тиеш түгел. Ир дә, хатын да үзләренең хис-кичерешләрен, хыялларын бер-береннән яшермәсен. Ир-ат ир-ат булып калырга хаклы, ягъни ул - гаилә башлыгы, яклаучы, саклаучы. Ә хатын-кыз хатын, ана, хуҗабикә булып калсын.

Кызганычка, дөнья куа торгач, күп кенә хатын-кызлар, үзләренең төп вазифаларын онытып җибәрде һәм иң матур сыйфатларын югалтты. Алар ирләргә охшарга тырышалар, яисә үзләрен ирләре белән аларның аналары кебек тоталар. Шуны онытмагыз: хатын-кыз ашарга әзерләгәндә дә, кунакта да, эштә дә, түшәктә дә хатын-кыз булып калырга тиеш. Хатын-кызларны хәзер китаплар укытыпмы, тренинглар ашамы, моңа яңадан өйрәтәсе бар. Ә иң яхшысы - кыз баланы кечкенәдән хатын-кыз итеп тәрбияләргә кирәк.

Сезгә шундый булып үзгәрергә омтылырга кирәк - ирегезгә башка бер генә хатын-кыз янында да сезнең яндагыга караганда уңайлырак булмасын. Үзгәрергә ниятегез барлыгын ирегезгә дә белгертегез. Сездәге нинди сыйфатлар аңа ошамый - шул турыда үзеннән сорагыз. Сабыр булыгыз, бу сорауга әле бер генә тапкыр әйләнеп кайтырга туры килмәс.

Ә сезнең көндәшегезгә килгәндә, аның үз иреннән китмәвенең сәбәбе - сезнең ирегезнең аның ихтыяҗларын канәгатьләндерәчәгенә ышанычы булмауда. Үз ире белән дә күңеленә тынычлык таба алмый, ахры. Гадәттә, ирләргә таләпләре югары булган хатын-кызлар икенче хатынлыкка ризалашмыйлар (икенче хатынлыкка алмаган очракта ирегездән ул хатын белән аралашуын туктатуын сорарга сезнең тулы хакыгыз бар). Ә ирегездән аерылып китү гаилә бәхетегезне шул хатын кулына тапшыру дигәнне аңлатачак (ул әле аның белән генә дә канәгатьләнмәскә мөмкин). Шулай булгач, бу хатынны җитди проблема итеп карамагыз. Проблема үзегездә, гаиләгездә, ирегез белән ике арадагы мөнәсәбәтләрнең камил булмавында. Ул хатын турындагы уйлар белән баш катырганчы ирегезгә ярарга тырышыгыз. Шул чагында, менә күрерсез, проблема үзеннән-үзе чишелер. Аллаһтан гаиләгезгә бәхет-бәрәкәт сорагыз! Кичләрен гаиләгез белән Коръән аятьләре һәм хәдисләр укуны гадәткә кертсәгез, йортыгызга бәрәкәт иңәр, иншә Аллаһ.

ISLAM-TODAY

ӘКИЯТ СӨЙЛӘП КОТЫЛА АЛМАССЫЗ

Мәгълүм ки, Татарстан сигез казыятка бүленгән, һәрбер казыятта казыйларыбыз - шәригать судьяларыбыз бар. Соңгы вакытта аларга икенче хатын алу белән бәйле сораулар, мөрәҗәгатьләр керә башлады.

Моннан дистә еллар элек кенә безнең җирлектә бу мәсьәлә юк иде шикелле. Хикмәт шунда - республикабызга Урта Азиядән эшкә дип бик күп егетләр килде, алар безнең кызларыбыз белән гаилә корып җибәрәләр, матур гына яши башлыйлар, балалары туа боларның. Күпмедер вакыт үтә, егет эшләп, бераз акча туплагач, хатынына берни әйтмичә, шыпырт кына үз ягына кайтып китә. Баксаң, аның тегендә дә хатыны, гаиләсе бар икән. Ә мондагы хатын инде аптырый, югалды дип милициягә хәбәр итә, эзләтә. Ир исә ни телефонын алмый, ни шалтыратмый, акча да җибәрми, талак та бирми. Менә шундый күңелсез хәлләр дә очраштыргалый.

Без бит инде дини гыйлем җитмәгән бер чорда яшибез. Ислам дине турында аннан-моннан гына ишетеп белгән яшьләребез, карале, ике-өч-дүрт хатын белән дә яшәргә ярый икән безгә, дип кызларны алдап-йолдап теләсә кемнән никах укыта башладылар. Андый никахлар мәҗлесләрендә ни әти-әни юк, ни шаһитлар катнашмый. Икенче хатынны син беренчесен тәэмин иткән кебек тәэмин итәргә тиешсең, безнең егетләр әнә шуны да белмиләр. Мәчеткә никах укытырга килгәч, кызның әти-әниләре бармы, дип сорыйбыз. "Бар, ну еракта яшиләр алар, килә алмыйлар", - дип әллә нинди әкиятләр сөйли башлыйлар. Шушы әкиятләр булмасын өчен яшьләребезне тәрбияләргә кирәк безгә, ике хатын белән торуның зур җаваплылык икәнлеген аңлатырга кирәк. Ятим балаларның күбәюе дә шул никахка җавапсыз карау нәтиҗәсе бит инде.

Мондый хәлләр бүгенге көндә алай күп булмаса да, киләчәктә зур проблемалар китереп чыгарырга мөмкин. Шушы хәлләрне күздә тотып, мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллин никахларны теркәүне тәртипкә салырга кирәк, дигән тәкъдим белән чыкты. Без моны бабайларыбызның элеккеге тәҗрибәләренә таянып алып барырга уйлыйбыз. Элек - революциягә кадәр һәрбер мәчеттә никахларны, балага исем кушуны ике китапка теркәп барганнар. Аның берсе - мөфтияткә тапшырылган, икенчесе үзләрендә калган. Ул документлар бүгенге көндә дә саклана, берәр әби таныклыгының дубликатын сорап килсә, ЗАГС хезмәткәрләре аны шул элекке мәчетләрдә иске имляда гарәп шрифтлары белән тутырылган кәгазьләргә нигезләнеп башкара. Менә без шул эшне торгызырга уйлыйбыз. Хәзерге вакытта "Гознак" компаниясе белән сөйләшүләр алып барабыз. Дини нәзарәте тарафыннан бөтен су билгеләренә хәтле булган бердәй шәһадәтнамәләр чыгачак. Электрон форматта аерым бер база булдырачакбыз. Никах укытырга килүчеләр турындагы мәгълүматны шул базага кереп карап булачак. Хатын-кызларны алдап-йолдап йөрүчеләрне, әһә, моның дүрт хатыны бар икән, бишенчене алырга маташа, дип шундук койрыгына басачакбыз. Киләсе ел башыннан, иншә Аллаһ, менә шушы эшкә ныклап керешергә ниятләп торабыз.

Рөстәм ХӘЙРУЛЛИН,
Татарстан мөфтие урынбасары

ИСЕМЕҢ МАТУР, КЕМНӘР КУЙГАН?

Ир-ат исемнәре

Афзал (г.) - иң лаеклы, иң кадерле
Ахир (г.) - соңгы, ахыргы, төпчек бала
Ахун (ф.) - туры юлга күндерүче, остаз
Аяз (бор.төр.-т.) - зирәк, зиһенле
Багдасар (бор.төр.-ф.) - яктылык, нур җыелмасы
Бадакшан (бор.төр.-т.-ф.) - зур белем, мәртәбә, шан иясе
Байбарс (бор.төр.-т.) - бай + барс (юлбарыс)
Байбулат (төр.-т) - бай + Булат
Байназар (төр.-т.-г.) - бай + Назар
Байсар (төр.-т.) - бай + сары

Хатын-кыз исемнәре

Бибихан (ф.-г.) - бикә, ханым
Бибкәй (Бибекәй) (ф.-т.) - бикә, ханым
Бикә (бор.төр.-т.) - хуҗа хатын, бәк хатыны, аксөяк хатын-кыз
Былбыл (г.) - сандугач; гүзәллек, зирәклек символы
Бостан (ф.) - бакча, гөлбакча
Бәдрия (г.) - тулган ай; иртәнге вакыт
Бәдиһә (г.) - чәчән хатын-кыз; тапкыр, җор
Бәнат (г.) - кыз бала
Бәрия (г.) - чүл, дала; җан иясе
Бәрәкәт (г.) - киңлек, муллык, байлык

Гомәр Саттарның "Исемең матур, кемнәр куйган?" китабыннан

ИМАМНАРГА ЫШАНЫЧ ЗУРДАН

Кукмара районы мөселман мәхәлләләре саны буенча республикабызда иң алдынгылардан санала: биредә дәүләт тарафыннан теркәлгән 72 мәчет эшләп килә. Мәчетмәхәлләләр белән җитәкчелек итүче хөрмәтле имам-хатыйблар авылларда бик кирәкле, үтә җаваплы хезмәт башкара. Чыннан да, бүген авыл тормышын мәчет бинасыннан, дини йолаларны үтәүче муллалардан башка күз алдына китерү кыен: халкыбызның ислам шәригате таләпләренә елдан-ел игътибары арта, аң-белемгә омтылуы, дин белән кызыксынуы үсә бара.

Соңгы елларда дәүләт, хакимият вәкилләре дә дин әһелләре белән аралашуны, алар белән киңәш-табыш итүне хуп күрә. Үзара мөгамәлә кору, аралашып, киңәшләшеп тору һәммәсе өчен дә нәтиҗәле булуын тормыш үзе исбатлап күрсәтә...

Яшәешнең һәр тармагында авырлыклар булган кебек дин әһелләренең дә үз проблемалары бар. Район имамнары ай саен җыелып, төрле мәсьәләләрнең хәл ителү юлларын эзлиләр, үзара гына сөйләшеп калмыйча, төрле дәрәҗәдәге дәүләт эшлеклеләре белән очрашалар. Корбан гаете алдыннан үткәрелгән җыелыш исә гадәти булмаган җыенга әверелде: ул көнне Үзәк мәчеттә Кукмара районына яңа җитәкче булып билгеләнгән Сергей Димитриев килде. Зур, җаваплы вазыйфага алынуына бер атналап кына вакыт узуга карамастан, яшь җитәкче район имамнары алдында шактый эчтәлекле, анык, мөһим мәгълүматка нигезләнгән чыгыш ясады. Үзе керәшен татарлары вәкиле булса да, Сергей Дмитриевич районда яшәүче мөселманнарны кайгыртыра, ихтыяҗларына битараф калмаска ышандырды, залда утыручы имамнарны Корбан гаете белән котлады.

Җыелышта катнашкан Кукмара районы прокуроры Минемулла Нәҗипов диннәрнең берсенең дә асылда начарлыкка өйрәтмәвен, яшь буынга балачактан ук рухи тәрбия бирү кирәклеген әйтеп узды. Шул ук вакытта динне үзенчә аңлаган, аны шәхси, сәяси максатларда мәкерле рәвештә файдаланырга тырышкан затларга карата уяу, игътибарлы булу да мөһим, дип билгеләп үтте прокурор. Бүгенге җәмгыятьтә рухи-әхлакый тәрбия эшендә имамнарның роле зур булуын ассызыклап, Минемулла әфәнде дин җитәкчеләрен тынычлык-иминлекне саклап калу өчен булдыра алганча тырышырга, яшьләрнең шикле агымнарга, ялгышхаталы юлга кереп китүләренә юл куймаска чакырды.

Татарстан Республикасы Президентының Эчке сәясәт мәсьәләләре департаменты баш киңәшчесе Ләззәт Хәйдәров республикабызда күп милләтле, төрле диннәр тотучы халык яшәвен искәртеп узды. "Кешеләр нинди диндә, нинди милләттән булуларына карамастан, барысы да илебезнең тигез хокукларга ия булган гражданнары. Үзара дус-тату, тыныч яшәү, җәмгыять яшәешендә хөрмәт-илтифатлылык принципларына таяну традицион саналган дини конфессияләрнең тәгълиматында чагыла. Мөселманнарда кардәшлек, күрше хакы кебек төшенчәләргә зур әһәмият бирелә. Гарәп халкы мәкалендә: "Яныгыздагы күршегез ерак туганыгызга караганда хәерлерәктер", - дип әйтелүе дә юкка түгелдер", - дип ассызыклады Ләззәт Хәйдәров.

Имамнар җыелышында Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте вәкилләре дә катнашкан иде. Мөфтинең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Илдар Баязитов физик мөмкинлекләре чикле булган кешеләр өчен оештырылган дини-рухи тернәкләндерү үзәге җитәкчесе буларак билгеле шәхес. Әлеге оешма әүвәл Казандагы "Сөләйман" мәчетендә урнашкан сукырлар җәмгыяте буларак эшләп килсә, хәзер ул төрле дәрәҗәдәге инвалидларны берләштерүче, ислам гыйлеме нигез итеп алучы "Ярдәм" үзәге булган. Былтыр шушы үзәк өчен башкалабызда зур, заманча җиһазландырылган матур бина төзелде. Илдар хәзрәт билгеләп үткәнчә, физик мөмкинлекләре чикле булган кешеләр һәр җирлектә дә бар - республикабыз районнарында яшәүче милләттәшләребез арасында да алар байтак. "Ярдәм" үзәгендә андый кардәшләребез өчен рухи реабилитация узу, дини белем алу, намазга өйрәнү өчен бөтен шартлар булдырылган. Мөфтиятнең шушы юнәлештәге тагын бер әһәмиятле проекты - Теләчедәге ятим инвалидлар өчен төзелә торган интернат. Аның турында мәгълүмат чараларында тулырак мәгълүмат әле бирелер.

Район имамнары алдында Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтенең яшьләр белән эшләү бүлеге мөдире Айнур Әхмәтшин да чыгыш ясады. Мөселман яшьләрен оештыру, берләштерү хакындагы фикерләре белән уртаклашканнан соң, Айнур хәзрәт җәмһүриятебездә оешып килүче волонтерлар хәрәкәте турында да сөйләп алды. Хәрәкәтнең максаты - шәһәр-районнарда үткәрелүче төрле чараларда хезмәт күрсәтү, өлкән яшьтәге кешеләргә, мохтаҗларга ярдәм итү һ.б.

Кукмара районы имаммөхтәсибе Зиннур хәзрәт Сәмигуллин җыелышта катнашучыларны Корбан гаете белән котлаганнан соң, район мөселманнары исеменнән күп еллар район башлыгы вазыйфаларын башкарган Рауил Рәхмәтуллинга рәхмәт сүзләрен юллады:

- Рауил Шәйдәүләт улына район мөселманнары бик рәхмәтле. Ул җитәкче булып торган елларда районыбызда мәчетләр төзелде, имамнар-абыстайлар өчен ифтар, Мәүлид ашлары үткәрелде. Гозерләре белән килгән мәхәллә җитәкчеләрен Рауил әфәнде беркайчан да кире бормады, һәрвакыт ачык йөз, җылы сүз белән каршы алды һәм озатты. 2008-2009 нчы елларда илебездәге тотрыксыз вазгыятькә, "кризис" чорына карамастан, Рауил Рәхмәтуллин дин әһелләренең үтенечләрен кире какмыйча, бистәбездә зур, заманча мәдрәсә бинасы төзетте, эшләрнең барышын тулысы белән шәхси контрольдә тотты. Хәзер бу бинада район мөселманнары - олысы да, кечесе дә - дини белем ала, аларның догалары, хәерхаһлы теләкләре бәрәкәтендә Рауил Шәйдәүләт улына да садака-иҗария рәвешендә әҗер-савап язылып барып, иншә Аллаһ...

Имам-мөхтәсиб районыбызга яңа җитәкче булып килгән Сергей Димитриевка да хезмәтендә уңышлар теләп, дин, әхлак, рухи тәрбия мәсьәләләрен күз уңында тотарга, бергә һәм бердәм булып, киңәшләшеп, ярдәмләшеп эшләргә насыйп әйләсен, дигән теләген белдерде. Имамнарга, дини белем бирүчеләргә мөрәҗәгать итеп исә, Зиннур хәзрәт болай диде:

- Бүген имамнарга ышаныч зурдан. Шушы җаваплы вазыйфаны безгә Аллаһы тәгалә ышандырып тапшырган. Күңелебездә авылдашларыбыз, динебез, гомумән, мөселман өммәте өчен ихластан борчылу булса, безгә Аллаһы тәгалә Үзе ярдәм итәчәк. Үзеңне пакьләндереп, башкаларны пакьләнергә өндәү - ихласлык һәм сабырлык таләп итүче зур хезмәтләр...

Имамнарның шушы олы хезмәтләре нәтиҗәле булсын, ахирәттә дә әҗерләрен күрергә язсын, Аллаһ Раббыбыз дин юлында иҗтиһад кылучы ихласлы бәндәләрен олуг ярдәменнән ташламасын.

Ришат КУРАМШИН,
Кукмара
мәдрәсәсе мөдире

ИЗГЕ БӘЙРӘМ АВЫЛДАШЛАРНЫ БЕР ТАБЫНГА ҖЫЙДЫ

Гает җиткән, азан ишетелә,
Сафландырыр вакыт күңелне.
Дөнья гаме баскан күңелләрне
Кузгатыр чак җитте түгелме?

Бәйрәм бүген, ыгы-зыгы тынган
Юллар ачык Раббың каршына.
Кул күтәреп сора, догаларның
Кабул була торган чагы ла.

Менә икенче ел авылыбыз мәхәлләсе җирле үзидарә белән бергәләп зурлап Корбан бәйрәме үткәрә. Гает иртәсендә авыл картларының җыелышып Аллаһ йортына тәкбир әйтеп төшүләре, хәзрәтнең изге бәйрәм белән котлап, авыл өстендә вәгазь сөйләве барча халыкның күңелендә бәйрәм рухы уятты. Гает намазы укылганнан соң, халык Аллаһы ризалыгы өчен ниятләгән корбаннарын чалырга ашыкты. Быел корбан чалучыларның башка елларга караганда күбрәк булуы куанычлы күренеш иде.

"Корбан" сүзе гарәпчәдән "якынаю", "якын булу" дип тәрҗемә ителә. Бәйрәмебезнең максаты да, беренчедән, Аллаһы тәгаләнең кушканын үтәп, корбаннар чалып, Аңа якынаю булса, икенчедән, кардәшләребез, туганнарыбыз, авылдашларыбыз белән очрашу, аралашны якынайту иде. Читтә яшәүчеләргә алдан ук чакырып хәбәрләр җибәрелде.

Мәдәният йортында башланган бәйрәм тантанасын азан әйтеп, Аллаһ юлына өндәгән шигырьләрен укып, гөнаһсыз сабыйларыбыз ачып җибәрде. Балаларның "Аллаһка юл - балалар күзлегеннән" дип аталган рәсемнәр күргәзмәсе һәм аппликацияләре дә, сөйләгән сүзләре дә, үз-үзләрен тотышлары да ихлас һәм эчкерсез иде. Равил хәзрәтнең, район советы депутаты Ирек абыйлары Вафинның бүләк һәм күчтәнәчләренә чын күңелдән сөенде алар.

Бәйрәмебезгә олы кунак - Түбән Кама районы имам-мөхтәсибе Йосыф хәзрәт Дәүләтшинның килүе нур өстенә нур булды. Аның белән ихлас әңгәмә, борчыган сорауларга җаваплар алу, йөрәкләребезнең һәр күзәнәгенә үтеп керерлек вәгазе иманыбызны тагы да баеткандыр. Авыл халкының моңа кадәр радио-телевидение, интернет аша гына күреп белгән зур хәзрәтне үз күзләре белән күрүе, тыңлавы Аллаһка якынаюга бер адым булгандыр.

Бәйрәм мәчеттә Корбан бәйрәме табыны артында дәвам итте. Мәҗлесне Йосыф хәзрәт Коръән укып башлап җибәрде, барча әрвахларның рухларына багышлап, чалган корбаннарыбызның Аллаһы тәгалә тарафыннан кабул булуын теләде, Аллаһы Раббыбызга һәрчак якынаерга омтылырга, кардәшләр белән туганлык мөнәсәбәтләрен сакларга, авылдашлар белән бердәм һәм тату булырга өндәде.

Бәйрәм табыны мулдан иде. Авылыбызга, мәчетебезгә һәрчак ярдәм итеп торучы Рафаэль Хәйруллин, керәшче батыр Рәйхан Асылов, авылыбыз егете Дамир Хөббәтуллин, читтә яшәүче бертуганнар Гөлзирә, Гөлсинә, Гөлфирә Салиховалар, Мирзанур абый Хабибуллиннар чалдырган корбан итләреннән, авыл халкының, кайткан кунакларның һәммәсенең дә күңел җылысы биреп әзерләгән күчтәнәчләреннән авыз иттек. Бәйрәмгә килә алмаган өлкәннәргә дә, инвалидларга да өлеш чыкты.

Шушылай зурлап үткәрелгән корбан бәйрәме, чыннан да, күптән күрешмәгән авылдашларны күрештерде, бер-берсенә якынайтты. Бәйрәмне оештырган, кардәшләрне очраштырган Равил хәзрәткә, җирле үзидарә башлыгы Гөлсинә Зәкәрия кызына һәм шушы бәйрәмгә өлеше кергән һәркемгә чын күңелдән рәхмәтләр әйтеп таралыштык.

Айсылу ИСЛАМОВА,
Азнакай районы,
Татшуган авылы

Хатларыгызны Диния нәзарәтенә(Лобачевский ур., 6 нчы йорт) яисә naubahar67@list.ru адресы буенча җибәрә аласыз

ШИҺАП ХӘЗРӘТ

Иске татар бистәсенең йортлары, урамнары яңартылганын ишеткәч, үз күзем белән күрергә теләп, Казан каласына килдем.

Шәһри Казан! Кайсы яктан гына карама, һәр милли җанлы кешегә якын ул. Югалган дәүләтебезнең кадерле ядкаре буларак та, дини мәркәз, милли үзәк булуы белән дә, Ватан төшенчәсенең символын чагылдыруы белән дә. Хәзерге көндә бу бик тә киңәйгән һәм зурайган шәһәрдә безне борынгы бабаларыбыз белән тоташтыра торган берничә урын арасында Иске бистә дип атала торган район бар. Кайчандыр милләтебезнең каһарманнары, зыялылары, галимнәре үскән йортлар, алар йөргән урамнар. Арабызны совет чоры аеруына карамастан, бистәнең күп кенә йортлары әле дә исән. Дөрес, Казан халкына бик кирәк тә түгел кебек ул. Казан халкы шул агач йортларда совет чоры буена сусыз, газсыз, уңайлыксыз яшәп җәфа чиккән, шуңа аның тарихи матурлыгын бик күреп бетерми. Үткән елларда күп кенә тарихи йортларны җимерсәләр дә, ниһаять, хакимият бу мәсьәләнең әһәмиятен абайлап алды һәм Универсиада алдыннан бистәне бик күркәм рәвешкә китерде.

...Троллейбустан төшеп Каюм Насыйри урамына кердек. Бу урам башында тарихи йорт - Шиһабетдин хәзрәт Мәрҗани йорты янына җиткәч, туктап уйга калам. Дөньякүләм шөһрәт тапкан галим шушы йортта яшәгән. Монда аның каләме астыннан мәшһүр әсәрләре чыккан, дөньяга таралган. Бервакыт галимнән: "Сез хезмәтләрегезне ник гарәп телендә язасыз?" - дип сорыйлар. "Мин хезмәтләремне мөселман галәмендә яшәгән башка халыкларның да укый алуын телим, шуңа гарәпчә язам", - дип җавап биргән хәзрәт. Бу аның глобаль фикерле, киң карашлы, даһи галим булуын күрсәтә. Һәм шулай булган да: аның хезмәтләре ислам дөньясында шөһрәт тапкан, шул чор галимнәре аңа зур бәя биргән, гыйлем белән әшнә булганнар әле дә Шиһабетдин әл-Мәрҗани дигән исемне танырлар.

"Иң шәп хәзрәт, Шиһап хәзрәт" дип Тукай да язган. Ул аны үз күзе белән күрмәгән, ләкин, һичшиксез, аның мирасы белән танышкан булса кирәк. Юкса тәнкыйтьче Тукай кемгәдер ияреп кенә берәр мулланы мактар идеме? Һич тә юк!

Мәрҗани йорты. Әле кайчан гына ул ташландык хәлдә иде, ә хәзер, гүя ки, хуҗасы әйләнеп кайткан да йортын яңарткан. Ханәсендә, үз бүлмәсендә Мәрҗани хәзрәт утыра төсле: ниндидер дини иә тарихи бер әсәр язып, әллә берәр китап укыпмы, әллә вакытын гаиләсе белән уздырыпмы. Чыннан да кызык бит, галим кеше өендә нинди булган икән? Ишегалдына керсәк, анда тәртип булганын күрер идек, ул бернәрсәне дә әрәм итмәгән, исрафтан ерак торган. Сазга баткан йомычка булса да, пәкесе белән каерып алып: "Казан астына ягарсыз, әрәм итмәгез", - дип ашханәсенә кертеп бирә торган булган. Икмәк сыныклары, җиләк-җимеш кабыклары булса да ташламыйча җыеп куеп, көтү кайткач үз кулы белән сыерга биреп ашаткан, ә орлык кебек нәрсәләр белән күркә, тавык, чебешләрен сыйлаган.

Аның өйдәге тормышын белергә теләсәк, бертуганының кызы Зәйнәпнең Мәрҗанидә туганнарына карата булган җылы мөнәсәбәтне тасвирлавын тыңлыйк: "Астрахань кебек күп җирләрдән укырга килгән шәкертләр көз көннәрендә Мәрҗанигә бик күп төрле җимеш күчтәнәч итеп китерәләр иде. Ул боларны гаилә эчендә һәркемгә үзе бүлә вә шуның эченнән үзенә дә бер өлеш алып куя иде. Шулай ук шәһәр халкы вә үзенә мөнәсәбәтле төрле кешеләрдән кияү бүләге вә мәкәрҗә бүләге кебек фруктларны да бүлә вә үзенә өлеш чыгарып комодына биклән куя иде. Үз кардәшләренең балалары үзенә килгәндә бу бүләкләрне әлеге балаларга биреп тота иде. Без йортында булганда, кичләрдә ул үзенең китапханәсендә уку белән мәшгуль, ә без йортның хатын вә кызларга махсус бүлмәсендә, җөй тегү кебек эшләр белән мәшгуль була идек. Бер вакыт укуына тәнәфес биреп, китапханәдән чыгып, кыштыр-кыштыр безнең бүлмәгә таба килгәне ишетелә башлый. Без аның килүенә җыенып җитәр-җитмәс безнең бүлмәгә килеп керә иде. Кулында әлеге фруктлар була вә аны безгә бүлеп биреп шатландыра вә шул мөнәсәбәт белән татар берникадәребез аңлардай кыйсса вә кызыклар сөйләп көлдерә иде".

Хезмәтләре галәми проблемаларны сыйдырган, ә гаиләсе өчен кече җанлы, йомшак күңелле кеше булган ул Шиһап хәзрәт.

...Менә азан тавышы яңгырый. Йорт капкасы ачыла, аннан чапан-чалмаларын кигән вәкарь Мәрҗани хәзрәт чыгар да, күңеленнән Корьәнен укып, салмак кына мәчетенә таба юнәлер сыман тоела...

Фатих ХӘБИБ

СОҢАРГАН НАМАЗ

Ашыга-ашыга икенде намазына әзерләнеп йөри идем. Намазлыгымны, дисбеләремне алдым да, тәрәзә янындагы тиешле урынга урнашыйм гына дигәндә, күзем йортыбыз каршындагы бакчага төште. Ә анда, безнең өй тирәсендә тукланып йөрергә күнеккән ике урам этенең берсе, кар бураннарын уйнатып, ниндидер кызгылт көрән төстәге җан иясе артыннан чаба. Этнең кыяфәтеннән ерткыч хайваннарның үз корбанын эзәрлекләгәндәге кебек усаллык, тәвәккәллек бөркелә: авызы зур итеп ачылган, колаклары арткарак салынып, озын ялларында җил уйный. Теге мескенкәем бәргәләнә-бәргәләнә ерткыч тешләреннән котылмакчы була. Эт аның саен тере йомгакны кабып ала да, тагын ычкындыра, аннары аны тагын куып тотарга тырыша. Менә сиңа "тычканга - үлем, мәчегә - көлке".

Эт бакчаны әйләндереп алган тимер койма янына барып җиткәч, инде тәмам хәлсезләнгән җан иясен кабат эләктереп алды да, институт тулай торагының спорт мәйданчыгына таба йөгерде. Эт авызындагы түмгәк песи баласына да охшаган, канатлары каерылган күгәрченне дә хәтерләтә. "Хәзер өзгәләп ташлый бит инде мескен җан иясен бу явыз эт", - дигән уй йөрәгемне өтеп алды да, тиз генә намазлыгымны һәм дисбеләремне караватка ташлап, кабалана-кабалана киенә башладым. Битемдәге таһарәт суы тамчыларын сөртергә дә онытып, кышкы салкынга чыгып йөгердем. Карчыгымның: "Кая йөгерәсең?"- дигән тавышына: "Хәзер керәм!" - дип кенә җавап бирдем дә, абынасөртенә баскыч буйлап түбәнгә ташландым.

Миннән аз гына да шикләнмичә, алларында яткан тере йомгакка азау тешләрен ыржайтып ике эт карап тора. Бер мизгел, һәм алар бу бәләкәй җан иясен ботарлап атачаклар. Теге явызларны хәтәр сүзләр кычкырып куып җибәрергә ачкан авызымны ябарга онытып туктап калдым... Өч пар күзнең күзәтүе астында яткан җан иясе кызгылт көрән төстәге нечкә билле пластик шешә иде. Әстәгъфирулла! Шук этләр шундук табышларын эләктереп, берсен-берсе куыша-куыша, бакча буйлап йөгерделәр.

Салкын һава кинәт кенә җылынып киткәндәй булды, янып торган битемне кышкы җилгә куеп, хыялый кешедәй үз алдыма елмая-елмая, өйгә атладым. Бу кадәрле җиңеллек, бу хәтле күңел тынычлыгы белән намаз укыганым юк иде әле. Йә, Раббым! Берникадәр соңлабрак укыган намазымны кабулларда кылсаң иде...

Мәгариф РАЯНОВ

РӘХМӘТ СЕЗГӘ, АБЫСТАЙЛАР

Бу сүзләрне күптән үзләренә әйтергә җыенып йөрсәм дә, һич җаен таба алмыйм. Чөнки, оятыма күрә, мин абыстайда укымадым, аларның бер генә дәресләрендә дә утырганым юк, һаман чабуымнан нидер тотып тора. Әмма мин аларга бүгенге көндә Корьән укый белә торган, дини гыйлеме булган милләттәшләрем өчен бик рәхмәтле.

Сүзем мәчетләрдә ислам дине дәресләрен укытучы абыстайлар турында. Ялгышмасам, инде менә утыз елдан артык дини яктан артта калган халкыбызга гыйлем бирәләр алар. Мин шактый борынгы кеше - "рәхим итеп, рәхәтләнеп укытыгыз" дип тормаган елларны да хәтерлим. Беренче абыстайлар шәкертләрен Мәрҗани мәчете подвалына җыйлар иде. Ахирәтем Зәйнәп: "Зал халык белән шыгрым тулы, урын җитми", - дип кайта торган иде дәрестән. Аннары "Нурулла"га, башка мәчетләргә дә җыелыша башладылар. Ул чакта хәзерге кебек шартлар юк, китап-дәреслекләр, программа-фәлән турында әйткән дә юк - иң мөһиме гыйлемгә сусаган халык бар, аларның күбесе бүген үзе абыстай булды.

Аллага шөкер, динсез-кыйбласыз, гыйлем-гамәлсез яшәргә ярамаганлыкны аңлаган халык елдан-ел арта бара. Һәм әле дә ликбезны татар абыстайлары җитәкли.

Төрле кеше бар бит, кайчакларда алар турында яратмыйчарак та әйтеп куялар. Бер начар сүз дә әйтмәгез, бер кырын караш та ташламагыз абыстайларга! Алар абруй казану өчен яисә матди якны кайгыртып түгел, бары тик Аллаһ ризалыгын алу өчен, үзләрендәге гыйлем белән бүлешергә тиешлеген аңлаганга күрә йөриләр. Һәм иң кызганычы шул - диндә әйдәп баручы татар ирләре аз булганга бу вазифа алар җилкәсенә калды (хатын-кызда бит милләтне саклап калу инстинкты көчле, диненнән язган милләт - нинди милләт ди инде ул?). Ә бит күбесенең үз мәшәкате дә хәттин ашкан: динсез ирне дин юлына бастыру, балаларын-оныкларын шәригать кушканча тәрбияләү дә алар өстендә. Аллаһы Раббыбыз сезгә шушы юлда көч-куәт, сәламәтлек бирсен, әҗер-савапларын язсын, хөрмәтле абыстайлар! Киләчәктә дилбегәне иманлы-гыйлемле татар ир-атларына ышанып тапшырырга насыйб булсын!

Миңзифа ЯППАРОВА, пенсиядәге укытучы

"ХУЗУР"МӘСКӘҮ ЯРМИНКӘСЕНДӘ КАТНАШТЫ

Россия Мөфтиләр шурасының социаль-хәйрия һәм рухи-мәгърифәтчелек эшчәнлеге буенча департаменты һәм Мәскәү шәһәре мөселманнары Диния нәзарәте Корбан бәйрәме уңаеннан "Йөрәкләр тугрылыгы" дип аталган зур чара уздырды. Әлеге чара кысаларында Мәскәүнең Музыка йортында үзенчәлекле китап ярминкәсе оештырылды. Мәскәү шәһәре мөселманнары Диния нәзарәте рәисе Илдар хәзрәт Галәветдинов чакыруы буенча ярминкәдә Татарстан Җөмһүрияте мөселманнары Диния нәзарәтенең "Хузур" нәшрият йорты да катнашты. Мәскәү укучыларына нәшрият чыгарган китаплар тәкъдим ителде.



***

"Хузур" нәшрият йорты имамнар, мөәзиннәр, мөгаллимнәр һәм киң катлам укучыларга аталган китапларны әзерләүне һәм нәшер итүне дәвам итә. Күптән түгел "Гыйбадәт кылуга кагылышлы кырык хәдис", "Мәңгелеккә юл тотучының ахирәт паспорты" китаплары дөнья күрде.

"Гыйбадәт кылуга кагылышлы кырык хәдис" китабында хәнәфи мәзһәбе буенча намаз укуга караган төп мәсьәләләр хәдисләр ярдәмендә аңлатыла. 40 хәдиснең чыганаклары күрсәтелә, татарча һәм гарәп телендәге язылышы бирелә.

Бу дөньяга килүебезнең, яшәү һәм китүебезнең максатын беләбезме? Мәңге калачак җиребез булган ахирәткә без ни дәрәҗәдә хәзерләндек? Гамәл дәфтәрләребездә ниләр язып куелган? "Мәңгелеккә юл тотучының ахирәт паспорты" исә әнә шундый сорауларга җавап табарга ярдәм итә.

"Хузур" нәшрият йортының рәсми сайты - huzur.ru; т.: (8843) 202-07-74.

"Хузур" нәшрият йорты республикабызның күренекле дин әһелләре, шәхесләре белән берлектә, "Татмедиа" матбугат агентлыгы ярдәмендә 8 аудиокитап чыгарды.

"Коръән аятьләренең татарча мәгънәләре һәм аңлатмалары". Коръән-Кәрим - Аллаһның сүзе, Изге китапларның соңгысы Пәйгамбәребез Мөхәммәд саллаллаһу галәйһи вә сәлламгә иңдерелгән. Коръән аятьләренең мәгънәләрен язучы, җәмәгать эшлеклесе Рабит Батулла аңлата.

"Әбү Хәнифә. Рухи һәм хокукый мирасы". Икенче диск. Аудиокитапта Әбү Хәнифәнең фикер, әхлак, иҗтимагый мәсьәләләргә карашлары, аның укучылары турында мәгълүмат бирелә. Шулай ук Әбү Хәнифәнең фикыһ ысуллары, ягъни ул кулланган дини дәлилләрнең төрләре бәйнә-бәйнә аңлатыла. Китап авторы - Мөхәммәд Әбү Зәһрә. Текстны Габдреләүф Нуриев укый.

"Әбү Хәнифә. Хәнәфи мәзһәбенең үзенчәлекләре". Өченче диск. Бу өлештә Әбү Хәнифәнең акыл кодрәтен күрсәткән аерым фикыһ мәсьәләләре тикшерелә. Хәнәфи мәзһәбенең барлыкка килүе, киңәюе һәм таралуы турында мәгълүмат бирелә.

"История ислама у татар". Россия ислам институты ректоры, сәясәт фәннәре докторы, тарихчы Рәфыйк Мөхәммәтшин лекцияләре. Ул татарларның Болгар чорыннан башлап, бүгенге көннәргә кадәрге тарихы турында сөйли. Текстны автор үзе укый.

"30 вәгазь". Вәгазьләрне Җәлил Фазлыев, Рөстәм Хәйруллин, Нияз Сабиров, Илдус Фәйзов, Габделхәмит Зиннәтуллин, Фәрид Сәлмән, Илфар Хәсәнов, Марсель Сабиров, Тимергали Юлдашев, Габдулла Әдһәмов, Булат Рәупов, Фәнис Мингәрәев, Илнар Зиннәтуллин хәзрәтләр сөйли.

"30 проповедей". Вәгазьләрне Рөстәм Хәйруллин, Нияз Сабиров, Илдус Фәйзов, Фәрид Сәлмән, Рөстәм Нургалиев, Руслан Фәрхетдинов, Рушан Садретдинов, Нияз Закиров, Алан Панарин, Сәеджәгъфәр Лотфуллин, Илнар Зиннәтуллин, Фәнис Мингәрәев хәзрәтләр сөйли.

"Сөекле Пәйгамбәребез (с.г.в.)". Урта яшьтәге балалар өчен булган бу аудиокитапта сөекле Пәйгамбәребезнең тормышы тасвирлана. Китапны аның авторы Рабит Батулла үзе укый.

"Матуридитская акыда" китабы ислам нигезләре, гакыйдә мәсьәләләре белән таныштыра. Аны РИИ мөгаллиме, "Әниләр" мәчете имам-хатыйбы Габдулла хәзрәт Әдһәмов укый.

ГАРӘП ТЕЛЕ КУРСЛАРЫНА ЧАКЫРАБЫЗ

Курсларда:

- укырга;
- катлаулы булмаган текстларны тәрҗемә итәргә;
- сөйләшергә

өйрәтәбез.

Курс 45 дәрескә исәпләнгән. Дәресләр атнага 2 тапкыр уздырыла.

Безнең адрес: Россия ислам институты, Казан шәһ., Газовая ур., 19 ("Ипподром" тукталышында төшәргә).

Курсларга дүшәмбе - җомга көннәрендә 13.00 дән 16.00 гә кадәр 8-9047614887 телефоны буенча язылырга була.

ИГЪТИБАР: "АВЫЛЫМ МӘЧЕТЕ" ФОТОКОНКУРСЫ!

Азнакай районы мөхтәсибәте сайты "Авылым мәчете" дип аталган республикакүләм фотоконкурс уздыра. Бәйге 20 октябрьдә башлана һәм 30 ноябрьгә кадәр дәвам итә. 15 декабрьгә кадәр сайтка урнаштырылган фотоларга тавыш бирергә мөмкин. 20 декабрьдә нәтиҗә ясала. Әлеге конкурста Татарстанның барлык авыл мәчетләре катнаша ала. Тулырак мәгълүмат - aznislam.ru сайтында.

ИСХАК ХӘЗРӘТ ЛОТФУЛЛА" КИТАБЫ ДӨНЬЯ КҮРДЕ

Совет хөкүмәте урнашкач, Казанда иң беренче кайсы мәчет төзелгән? Бик тиздән татар халкының бөек композиторы булып таныласак "Мөхәммәдия" мәдрәсәсе шәкерте Салих Сәйдәшев әзләрен саклаган иман йортын беләсезме? Дин иреге килгәч, 17 ел имам-хатыйб, 7 ел мәдрәсә ректоры, мөгаллим, нәшир булып торган, яңа заманда имамлык, хәйриячелек эшен кабаттан торгызган дин әһеле кем ул? Бүген Казанның яшь имамнары арасында нәселендә дүрт буын муллалар булган, үзе дә шушы вазыйфаны дәвам итүче кем дип беләсез? Әлеге сорауларга җавапларны "Идел-пресс" нәшриятында зур тираж белән дөнья күргән "Исхак хәзрәт Лотфулла" китабында таба аласыз. Кабан арты мәчетендә әтисе башлаган эшне дәвам итүче Сәеджәгъфәр хәзрәт Лотфулла, гаилә ядкарьләрен туплап, китап итеп чыгаруга зур тырышлык куйган. Китапның мөхәррире - журналист Василә Рәхимова.



ДИН вә Мәгыйшәт

Октябрь саны, № 10 (231)

Гамәлгә куючы: Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте *(420111 Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6/27)* .
Нәшир: "Хузур" нәшрият йорты *(420111 Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 10в).*

Мөхәррир: Нәүбәһар КӘБИРОВА
Дизайнер: Гүзәл МИҢНУЛЛИНА
Корректор: Айгөл КРОХИНА
Газета логотибы **хәттат** Рамил НАСЫЙБУЛЛОВ тарафыннан эшләнде

Редакция советы:
*Татарстан мөфтие, Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте рәисе **Камил СӘМИГУЛЛИН**;*
*"Хузур" нәшрият йорты директоры **Ришат ХӘМИДУЛЛИН**;*
*Татарстан мөфтие урынбасары **Нияз САБИРОВ**;*
*Татарстанның баш казые **Җәлил ФАЗЛЫЕВ**;*
*Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәтенең Голәмалар шурасы рәисе **Габдулла ӘДҺӘМОВ**.*

Газета Татарстан Республикасы матбугат һәм мәгълүмат министрлыгында 1993 нче елның 16 нчы февралендә 240 нчы номер белән теркәлгән.
Материалларны күчереп бастырганда кайдан алынганлыгын, авторларын күрсәтү мәҗбүри.
Газета "Татмедиа" ААҖ филиалы – "Идел-Пресс" полиграфия-нәшрият комплексында басылды (420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2).
Заказ № 09616
Тираж: 5 мең данә
Газетаны ваклап сатуда тәкъдим ителгән бәя – 6 сум.
График буенча бу санга **26 нче октябрь көнне 18.00 сәгатьтә** кул куелырга тиеш иде. **Кул куелды: 18.00 сәгатьтә.**

Редакциянең һәм нәшер итүченең адресы:
420111, Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6/27.
Электрон адрес: naubahar67@list.ru
Телефон: +7 (843) 267-29-67.

Язылу индексы: 16046
Татарстанның һәр почта бүлегендә язылырга мөмкин.

Газетада Аллаһы тәгаләнең исемнәре, Коръәннән аятьләр бар, тиешсез урынга кулланудан сакланыгыз!